КЕСӘГӘ СУГАЧАК

Яңа кагыйдәләр такси бәяләрен шактый арттырырга мөмкин

> 5

ХАТАЛАРНЫ ТӨЗӘТӘСЕ!

Республика мәгариф хезмәткәрләренең август киңәшмәсе узды

> 15

НӘСИМ АКМАЛ:

«Үзебез кадерләмәсәк, башка халык килеп кадерләмәячәк»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 119 (29086) | Җомга | 18 август | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

ҮЗГӘРЕШ ҖИЛЕ

СУМ БЕЛӘН ДОЛЛАРНЫҢ ЯРЫШЫ НӘРСӘГӘ КИТЕРЕР?

Сум төште, ставка менде. Мәгълүм булганча, Үзәк банк төп ставканы 8,5 проценттан 12 процентка кадәр күтәрде. Хәзер нишләргә? Яңа икътисадый чынбарлыктан нәрсә көтәргә? Булган акчаны нишләтергә? Кулда булган доллар белән нишләргә? «ВТ» халыкны да, бизнесны да борчыган бу һәм башка сорауларга җавап эзләде.

> 6

Ишетми калмагыз

Татарстанның торак пунктларында су белән тәэмин итү челтәрләрен төзү һәм төзекләндерү эшенә 54,8 млн сум акча тотылачак. Аерым алганда, сүз Казан, Балык Бистәсе, Әлмәт, Актаныш, Саба җирлекләрендәге ремонт эшләре турында бара.
Әйтик, Балык Бистәсендә 1 мең метр озынлыктагы суүткәргеч төзү, эчә торган су саклау резервуарын кую, насос станциясен сафка бастыру һәм су әзерләү станциясен төзүгә 25,8 млн сум акча тотылачак.
Әлмәт районындагы Урсал микрорайонындагы эшләргә 15 млн сум акча бүлеп биреләчәк. Биредә 1987 метр су челтәре төзү һәм насос станциясенә ут кертү каралган.
Казанның Җиңү проспектыннан башлап Салмачы бистәсендәге Үзәк урамга кадәр су челтәре сузу планлаштырыла. Моның өчен 2 млн сум акча тотылачак. Актаныш районының Иске Кормаш авылында 2159 метр тышкы су белән тәэмин итү челтәрләрен реконструкцияләү 6 млн сумга төшәчәк. Саба районының Миңгәр авылында 1480 метр озынлыктагы су белән тәэмин итү челтәрләрен төзү өчен дә шулкадәр акча тотылачак.
Бу эшләрне агымдагы елның 30 ноябренә кадәр тәмамларга тиешләр.

Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы яңа төрле алдау ысулы хакында кисәтә. Бу юлы кырыгалдарлар халыкка пенсия һәм торак-коммуналь хезмәтләр өчен исәп-хисап ясыйбыз дигән тәкъдим белән акча урлый башлаган. Казанда шундый очрак теркәлгән инде.
Полициягә башкалада яшәүче 77 яшьлек ханым мөрәҗәгать иткән. Мошенниклар аның 900 мең сум акчасын урлаган. Зыян күрүче сүзләренә караганда, кырыгалдар, телефоннан шалтыратып, үзен «социаль яклау бүлеге белгече» дип таныштырган, пенсия һәм торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча исәп-хисап эшләргә кирәк дип әйткән. Матди компенсацияне пенсия счетына җибәрәбез дигән тәкъдим белән, шәхси мәгълүматны соратып алганнар. Барлык күрсәтмәләрне үтәгәннән соң, пенсионер ханым акчасыз калуын аңлаган.

Казан аэропорты ярты ел эчендә 2294239 пассажирга хезмәт күрсәткән. Шуларның 1,7 миллионнан артыгы эчке рейслар булса, 587 меңнән артыгы – халыкара. Беренче ярты еллык нәтиҗәләре буенча, Мәскәү, Санкт-Петербург, Сочи, Минераль Сулар һәм Новосибирскига очышлар башкарылган. Халыкара рейсларларга килгәндә, популяр юнәлешләр арасында Анталья, Истанбул, Дубай, Душанбе һәм Хургада бар. Узган елны аэропорт 4 млн пассажирга хезмәт күрсәткән иде. Быел Казан аэропорты рекорд куярга – 5 млн кешегә хезмәт күрсәтергә ниятли.

Районнарда ни хәлләр?

Сарман

Урта Кәшер авылында гомер кичерүче Нәфисә Насыйбуллинага 100 яшь тулды. Юбилее белән котларга килгән кунакларны ул капка төбенә үк чыгып каршы алды. Йөзьяшәр ветеранны район башлыгы Фәрит Хөснуллин тәбрикләде, Татарстан Рәисенең Котлау хатын, истәлекле бүләкләр, күчтәнәчләр тапшырды.
(«Сарман-информ»)

Әгерҗе

Әгерҗе стадионында пляж волейболы мәйданчыгы ачылды. Ул «Демография» илкүләм проекты кысасында җиһазландырылды. Волейбол мәйданчыгы ачылганнан соң монда яшьләр һәм үсмерләр тагын да күбрәк йөрер дип ышаналар. «Балаларыгыз белән бергә килегез, стадионда сәламәт яшәү рәвеше алып бару өчен бар уңайлыклар да бар. Кичен волейбол мәйданчыгы яктыртыла», – диде аны ачу тантанасында район башкарма комитетының социаль үсеш бүлеге җитәкчесе Илшат Гарифуллин.
(«Әгерҗе хәбәрләре»)

Саба

Саба районының Балалар иҗат үзәгендә аз керемле һәм күпбалалы гаиләләрдә тәрбияләнүче 70 укучыга мәктәп кирәк-яраклары тапшырылды. Чара «Мәктәпкә җыенырга булыш!» акциясе кысасында узды. Әлеге балаларның 20се – 1 нче сыйныфка баручылар. Район башлыгы Рәис Миңнеханов әти-әниләрне, балаларны тәбрикләде, әлеге изге эшкә кушылган оешма-предприятие җитәкчеләренә, шәхси эшмәкәрләргә рәхмәт сүзләре җиткерде.
(«Саба таңнары»)

Түбән Кама

Район хастаханәләрендә иллегә якын яңа белгеч эшли башлаячак. Түбән Кама районы башлыгы Рамил Муллин белдерүенчә, шәһәр хакимияте биналар төзү белән берррәттән ул биналарда профессионаллар эшләвен дә тәэмин итәргә тиеш. «Безнең бурыч – 2–3 ел дәвамында хастаханә шәһәрчегендә планлаштырылган ремонт эшләрен тәмамларга», – диде ул.
(«Туган як»)

Азнакай

Районда рәсми рәвештә агымдагы елда 200 нче бала тууы теркәлде. Светлана һәм Ренат Гаффаровлар гаиләсендә 10 яшьлек Илдан һәм 5 яшьлек Рианага иптәшкә уллары Ислам дөньяга аваз салды. Гаиләне район башлыгы Марсель Шәйдуллин котлады. «Улыгыз Исламның киләчәктә сезнең өчен терәк һәм ныклы таяныч, горурлыгыгыз һәм яклаучыгыз булуын телим!» – диде ул.
(«Азнакай-информ»)

НӘТИҖӘЛӘРНЕ САНАР ЧАК

tatarstan.ru

Татарстан бишенче ел рәттән инвестицион климат торышы буенча Илкүләм рейтингта икенче урынны саклап кала. Әмма төбәк әлеге казанышларда туктап калырга җыенмый. Хөкүмәт йортында «Нәтиҗәле төбәк» сынау проектын гамәлгә ашыру буенча Татарстан Министрлар Кабинетының һәм Координация советының уртак утырышында әнә шундый фикер әйтелде.

Видеоконференцияне Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин үткәрде. Анда Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов, «Росатом» дәүләт корпорациясенең «Росатом» җитештерү системасы» җәмгыяте проекты җитәкчесе Дмитрий Репьев, Татартан Рәисе Администрациясе һәм Татарстан Министрлар Кабинеты, министрлыклар һәм ведомстволар, республика оешмалары һәм предприятиеләре вәкилләре катнашты.

Алексей Песошин әйтүенчә, республика позицияләрен яхшырту өчен резервлар һәм юнәлешләр бар. Төп бурычларның берсе – барлык тәкъдимнәрнең һәм үзгәрешләрнең инвесторлар өчен уңайлы шартлар тудыруга ярдәм итүе. Билгеле булганча, республикада «Үтәли инвестицион агым» проекты дәвам итә. Эш инвестиция проектларын гамәлгә ашыруда кирәкле төп процедураларны оптимальләштерү өчен 9 алгоритм буенча алып барыла.

Рөстәм Миңнеханов «Үтәли инвестицион агым» проектын уңышлы тормышка ашыру һәм инвесторларга уңайлы шартлар тудыру өчен берничә бурычны үтәргә кирәк булуын ассызыклады.

– Бу, беренче чиратта, квалификацияле кадрлар әзерләү, төгәл регламентларны билгеләү һәм үтәү; махсус җир кишәрлекләре әзер булырга һәм инвесторга тапшырылырга тиеш. Болар барысы да инвесторлар белән эшне тизләтәчәк. Нигездә, бу юнәлешләрдә эш оештырылган. Регламентларны катгый рәвештә үтәү генә кирәк. Без реаль нәтиҗәләрне күтәрбез, – диде ул.

Рөстәм Миңнеханов ассызыклаганча, «Үтәли инвестицион агым» проектын гамәлгә ашыру дәвам итәчәк, хакимият органнарына һәм ресурслар белән тәэмин итүче оешмаларга эшкә җитди карарга кирәк. Эшне җайга салуны Татарстан Икътисад министрлыгы дәвам итәчәк.

Татарстан Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасары, Казан дәүләт энергетика университеты проректоры Ирина Әхмәтова фикеренчә, әлеге проектлар, беренче чиратта, халыкка уңай шартлар булдырылсын өчен тормышка ашырыла.

– Әлеге проектларда энергетикага бик зур урын бүлеп бирелгән. Аерым алганда, технологик тоташтыру, электр җылылык челтәрләрендәге аварияләрне төзәтү, яңа объектларны тоташтыру буенча эшләрне күпкә җиңеләйтү өчен каралган, – диде ул. – Шуңа күрә бу проектларның барысы да беренче чиратта халык өчен эшләнә. Татарстан бу проект белән ярты еллап шөгыльләнә инде. Бездән кала Россиянең башка төбәкләре дә проектны тормышка ашыра. Мин «Умный город» проекты турында да әйтеп узар идем. Монда рейтинг цифрлы кабул итүләр буенча алып барыла. Анда да энергетикага кагылышлы зур блок бар. Быел республиканың ике шәһәре – Казан һәм Алабуга лаеклы номинацияләрдә өченче урыннарга лаек булды. Казан Россиянең бары тик ике зур шәһәрен генә алга җибәрде. Бу – бик яхшы күрсәткеч. Шундый саллы проектларда үзебезне күрсәтә алабыз икән, димәк, «Нәтиҗәле төбәк» проекты да Татарстан өчен яхшы күрсәткеч булачак.

Ярдәм йөге

БИЛӘҮСӘ ДӘ КИРӘК

«Тормыш дәвам итә». Казаннан Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләренә чираттагы гуманитар ярдәм китте. Бу юлы машиналарда нарасыйлар өчен кирәк-ярак та бар.

Гуманитар йөк төялгән фуралар «Игелекле Казан» фонды белән берлектә Казан башкарма комитеты тарафыннан әзерләнгән. Унынчы мәртәбә җибәрелә торган ярдәмнең күләме – 85 тонна. Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләренә бу юлы төзелеш материаллары, азык-төлек, көнкүреш химиясе, махсус киемнәр, китаплар, моннан тыш, яңа туган сабыйлар өчен кирәк-ярак алып киттеләр.

– Казанда яшәүчеләргә һәм эшмәкәрләргә битараф булмаулары өчен рәхмәт. Бу юлы без беренче мәртәбә яңа туган балалар өчен ярдәм җибәрәбез. Тормыш дәвам итә. Лисичанскида һәм Рубежныйда яшәүчеләр, биләүсә, подгузниклар һәм сабыйлар өчен башка кирәк-ярак табу авыр, дип, безгә мөрәҗәгать итте. Ярдәм итә алуыбызга шатбыз, – ди Казан мэры Илсур Метшин.

Узган елның ноябреннән бирле Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләренә казанлылар һәм эшмәкәрләр тарафыннан җибәрелгән гуманитар ярдәмнең гомуми күләме 1100 тоннага җиткән.

Нарасыйлар өчен меңләп махсус мендәр, 700ләп юрган, 300ләп бәйләнгән оекбаш, баланы төрү өчен махсус келәмнәр, кием-салым җибәргәннәр. Бу ярдәмне җыярга Казанның «Игелек кыл» хәйрия фонды ярдәм иткән.

НИ ХӘЛЛӘРДӘ ЯШӘП ЯТАСЫЗ?

Халык кәефе

Көтеп алган җәйнең соңгы көннәрен ваклап маташабыз. Күңелле дә, бераз моңсу да чак. Укучыларыбыз ни хәлләрдә яшәп ята икән?

Гөлназ ГӘРӘЕВА, укытучы (Мамадыш районы Көек-Ерыкса авылы):
– Авылда эш бетми. Бакча белән беррәттән кош-корт та бар. Әле менә бройлернын эшен бетереп, бераз ял иткәч, үрдәкләрне эшкәрттек. Тавыклар басып чыгарган 30лап чебешем генә калып бара. 100ләп банка компот, төрле кайнатмалар ясаудан тыш, күп итеп алма киптердек, 30га якын как ясадым. Икешәр чиләк кызыл помидор җыйган көннәр күп, Аллаһка шөкер. Баштарак әле тансык вакытта күчтәнәчкә өләшкәләдек, аннан инде эшкәртә башладык. Уңыш бик мул, шөкер, бары да бар: сарымсаклар эре һәм күп, сатар өчен дә үстерәбез, суган җыелды, бәрәңгене Корбан гаетендә авыз иткәннән бирле ашыйбыз. Иртә өлгерә торган кызылын инде рәттән казый башларга исәп. Көннәрнең кызулыгы гына туктатып тора. Дөресен генә әйткәндә, бу эссе көннәр бик ардырды. Мин салкын кышны, алтын көзне күбрәк яратам. Булган сәламәтлекне югалтмыйча, тигезлектә, балалар игелегендә уңышны җыеп алып, ел әйләнәсе шулар белән сыйланып, җиң сызганып төп эшкә тотынасы инде. 1 сентябрь – ишек төбендә, уку башлана, эш башлана. Иң зур теләк: илләргә иминлек, тынычлык килсен, киткәннәр исәнләтә гаиләләренә кайтсын.

Әлфия СӘЛАХОВА, хуҗабикә (Яңа Чишмә районы Зирекле авылы):
– Кәеф яхшы, Аллаһка шөкер. Җәйнең соңгы көннәренең тәмен тоеп калырга тырышабыз. Хискә бирелеп утырырга гына вакыт юк. Әле менә алмадан повидло ясап маташам. Быел кайнатмалар бик күп әзерләдем, шөкер. Кичкә ташкабактан салат ясыйм, Алла боерса. Кыяр, помидор да күп тозланды. Илләр тыныч булып, булган уңышларны исән-сау үзебезгә ашарга язсын инде. Бу көннәрдә бәрәңгегә тотынырбыз дип торабыз. Безнең якта халык бәрәңге ала башлады инде. Сәламәтлек кенә булсын. Авырмас өчен, гаиләбез белән үлән чәйләре генә эчеп торабыз.

Алмаз МИРЗАЯНОВ, җырчы:
– «Болгар» радиосы оештырган велосәяхәттә әле без. Бездән соң велосипедта килүчеләрне көтеп торабыз менә. Аңа кадәр Иске Рәҗәп авылында булдык. Шулкадәр көтеп алганнар! Авыл башында ук кочаклап каршы алдылар, мул табын янында авыл хәлләрен сөйләшеп утырдык. Бик рәхәт, җылы очрашу булды. 25 сентябрьдә Башкортстанда гастрольләребез башланачак, Аллаһ боерса. Кызыбыз Нәзирәдән рөхсәт сорадык инде *(көлә)*. Кызыбызга тугыз ай булды, атларга маташа. Аның яныннан бер дә чыгып китәсе килми, шулкадәр рәхәт.

Гөлчирә НӘҖМЕТДИНОВА, үләннәр белән дәвалаучы (Арча районы Наласа авылы):
– Узган елның октябрь аеннан башлап быел июньгә кадәр ике күзгә дә бик катлаулы биш операция ясаттым. Табибым иелеп эшләмәскә кушты. Быел чия, кура җиләге бик күп булды. Берсен дә эшкәртмәдем. Туганнарга күчтәнәч итеп өләштем. Кыяр, помидорлардан да берни дә ясамадым. Берүзем яшим. Мин андый әйберләрне бик ашамыйм да хәзер. Шигырьләр язам. Китап чыгарырга ниятлим. Татарстан китап нәшриятына бер китаплык иҗат җимешләремне бирдем.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Җитештерүдә югары күрсәткечләргә ирешүләре һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен «Казан вертолет заводы» акционер җәмгыятенең очу аппаратлары электр җиһазлары монтажчысы **Артамонов** Виктор Владимирович, «Туполев» гавами акционер җәмгыяте филиалы – С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводының термик цехы ванналарында термисты **Әсәтова** Индусә Әхтәм кызы, «Түбән Кама механика заводы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җыю производствосына хезмәт күрсәтү цехы автоматика чаралары һәм технологик җиһазлар приборлары буенча электромеханигы **Залялов** Марс Санзабетдин улы, «Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте әйдәүче инженер-технологы **Моисеев** Александр Викторович, «Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыятенең 15 номерлы цехы химия производствосы мастеры **Фәхретдинова** Лилия Кыяметдин кызы, «Туполев» гавами акционер җәмгыяте филиалы – С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводы җыю эшләрен тәмамлау производствосының техник контроль бүлеге сыйфат буенча инженеры **Чижиков** Владимир Иванович **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен»** медале белән бүләкләнде.

***

«Лениногорск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең балалар стационары педиатрия бүлекчәсе мөдире – табиб-педиатры **Кәримова** Сания Ибраһим кызына, «Гаилә сәламәтлеге Д» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте табибы – акушер-гинекологы **Лобова** Людмила Александровнага, «Сарман үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең Александровка табиблык амбулаториясе гомуми практика табибы (гаилә табибы) **Мәүләвиев** Шәрифҗан Сәхипҗан улына, «Айболит» медицина үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Рызванов** Азат Абдулхак улына, Казан шәһәренең «Сугыш ветераннары госпитале» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең баш миендә кан әйләнеше кискен бозылган авырулар өчен неврология бүлекчәсе табиб-кардиологы **Хафизова** Мөнирә Мөхәмәт кызына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор М.З. Сигал исемендәге Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы **Һидиятов** Илгиз Ринат улына **«Татарстан Республикасының атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Лаеш үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең Атабай фельдшерлык-акушерлык пункты мөдире – фельдшеры **Әмирова** Рания Закир кызына, «Буа үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең ультратавыш диагностикасы кабинеты шәфкать туташы **Әхмәтҗанова** Зифа Әхмәт кызына, «Мамадыш үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе поликлиникасының гомуми практика табибы шәфкать туташы **Гәрәева** Гөлсинә Мохлис кызына, «Лаеш үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең Нармонка фельдшерлык-акушерлык пункты мөдире – акушеркасы **Закирова** Наилә Рифат кызына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең радиацияне контрольдә тоту төркеме табибы-рентгенологы **Нигъмәтуллина** Айгөл Рошаль кызына, «Буа үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең хирургия бүлекчәсе операция шәфкать туташы **Санатуллова** Наилә Әнвәр кызына **«Татарстан Республикасының атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе юридик факультетының җинаятькә каршы көрәшү хокукы кафедрасы доценты, «Россия юристлары ассоциациясе» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсе әгъзасы **Бакулина** Лидия Васильевнага, «Төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасының дәүләт экспертизасы һәм бәяләр кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе эшчәнлекне хокукый тәэмин итү һәм сатып алулар бүлеге башлыгы **Ильясова** Гөлназ Әсхәт кызына, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы **Миңнуллина** Римма Шамил кызына, Татарстан Республикасының Әлмәт нотариаль округы нотариусы, «Россия юристлары ассоциациясе» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсе әгъзасы **Исламова** Эльвира Әбүзәр кызына, Татарстан Республикасы Казан шәһәре Вахитов районы прокуроры урынбасары **Мостафин** Марат Зөфәр улына, «Татарстан Республикасы Казан шәһәре Яңа Савин районының адвокатлык үзәге» адвокатлар коллегиясе адвокаты, «Россия юристлары ассоциациясе» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсе әгъзасы **Чернышова** Вера Михайловнага **«Татарстан Республикасының атказанган юристы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Новая Заря» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең авыл хуҗалыгы производствосы тракторчы-машинисты (Татарстан Республикасының Тәтеш районы) **Әхмәтов** Насих Вазыйх улына, «Август-Кама Тамагы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең авыл хуҗалыгы производствосы тракторчы-машинисты (Татарстан Республикасының Кама Тамагы районы) **Бакиров** Фаяз Вәкил улына, «Август-Лениногорск» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең авыл хуҗалыгы производствосы тракторчы-машинисты (Татарстан Республикасының Лениногорск районы) **Газизов** Илгиз Зәки улына, «САРМАН» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең авыл хуҗалыгы производствосы тракторчы-машинисты (Татарстан Республикасының Сарман районы) **Газизов** Ленар Әнвәр улына, «Туган як» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Мөслим районы) **Сөләйманов** Илнар Бәшир улына, «Чиялек» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Шаехов** Азат Асаф улына, «Мөхәммәтшин Зөфәр Зиннәт улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы механизаторы (Татарстан Республикасының Саба районы) **Шакиров** Рәис Мансур улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Түләүсез бит

Ни өчен шулайдыр инде ул, әмма бушлай биргәнне бөтен кеше дә ярата. Түләүсез алган фәлән кило нәрсәсен ул фәлән чакрым күтәреп алып кайтырга мөмкин. Җәяүләп. Сатып алса, алай итми, такси чакыра. Бер таныш бар, бездән ерак түгел генә яши. Көз җитә башласа, бөтен күрше-тирәсе моңа алма кертеп бирә. Ялгызы гына яши ул ир. Мал да асрамый, кош-корт та тотмый. Варенье да кайнатмый, компот та куймый. Алма ул капчыклап ашый торган нәрсә түгел бит инде. Тик колхоз бакчасыннан тагын берничә капчык алып кайта. Череп, сасып, чебенләп ята башлагач, тегеләрне тагын капчыклап чүплеккә илтеп түгә.

Без күреп-нитеп калсак, үзебезчә көлгән булабыз инде, ирештерергә маташабыз. Кешедән көлүдән дә рәхәтрәк нәрсә юк бит инде – аның һәрбер кимчелеге үзеңнең өстенлегең кебек кадерле була. Ә асылда беребез дә аннан артыграк түгел. Бер җәйне бер абзый балыкчылар янында кунак була. Берәр файдасы тигәндер инде, әйбәтләп кунак итәләр. Бу күчтәнәчкә балык сорый. Тегеләр әйтә инде: «Әнә суыткычтан күпме телисең, шулхәтле ал», – диләр. Зерә әйтәләр моны. Теге абзый ачыклый башта, чынлап та бушлай бирәләрме. Бушлай икәнен белгәч, «Газель» салонын балык белән тутыра. Юл озын гына бит инде, җәй эссе. Кояш кыздыра, балык сасый. Авылга кайтып кергәнче, бер балыгының да балык дип әйтерлек җире калмый. Кайткач та капка төбенә генә бушата торган нәрсә түгел бит. Тик бу алай да итми, арасында арураклары да калгандыр әле, дигән өмет белән тегеләрне келәтенә ташый. Әйбәтрәк кебек тоелганнарын мичкәгә тозлап куя, начарракларын тавыкка ашатырмын дип аерып җыя. Суыткычлары балык белән тула. Кар базына да салалар. Бөтен тирә-якларын сасыган балык исе баса… Соңыннан аның «Газель»ен бер чакрымнан таный башладылар. Исеннән. Бушлай бирмәсәләр, шулхәтле төяп кайтмас иде.

Читтән мисал эзләп тилмереп йөрисе түгел, үзем дә шулайрак эшләдем. Компьютер алып, интернет кушып җибәрдек. Тегендә әллә нинди яхшы китапларны бушлай күчереп алып була икән. Мин дә күчердем. Компьютер күз алдында симереп киткән кебек булды, акрынрак эшли башлады. Югыйсә ул китаплар бүген дә, иртәгә дә булачак бит инде интернетта. Ә кем белә? Бушлай чагында күчереп алып куярга кирәк. Балыгын кар базына тутырган абзый шикелле, мин дә китапларны дискларга күчердем.

> Беребезне алып, беребезне куярлык түгел. «Бушлай» килгән әйбер янында барыбызның да күзләре томалана, акылы артка кача, ахмаклыгы ханга әйләнә. Югыйсә бөтенләй үк түләүсез дә түгел бит.

Теге абзый менә дигән машинасын сасытты, мәсәлән, балык исен бетерү өчен нинди генә нәрсәләр белән юып карамады. Үземә хәзердән үк кирәге булмаган әйберләрне күпләп күчереп, мин дә компьютерны тыгылдырдым, трафикны арттырган өчен түләдем. Чынлабрак уйлап карасаң, бушка килгән нәрсәләр өчен һәрвакыт түләргә мәҗбүр буласың икән бит.

Без моны барыбыз да беләбез. Кирәк булса, үз тормышыбыздан да, башкаларныкыннан да әллә күпме мисаллар китерә алабыз. Җитди кыяфәт чыгарып: «Дөньяда бушлай нәрсә булмый, һәр очракта да түләргә туры килә, кайчак артыгы белән», – дип фәлсәфә сатабыз. Һәм берәр җирдә берәр нәрсәнең бушлай икәнен белсәк, бөтен дөньябызны онытып, шунда чабабыз.

Әйтеп кенә бактым

Иртәнге вәсвәсә

Риман
ГЫЙЛЕМХАНОВ

Дачада һәркөнне күрше әтәче тавышына уянам. Бер үк вакытта, таң сызылганда кычкыра башлый ул, үзенә күрә көе дә, сүзе дә бар. «Кикрикүк» дими, «р» хәрефен ничек әйтә алсын инде ул, «кукиуку» ди, һәрхәлдә, миңа шулай ишетелә. Хәтта тональностен дә үзгәртмичә, һәр 40 секунд саен кычкырып куя. Монысын үзем санап яттым.

Авыл кешесе әтәчсез таң атуны күз алдына да китерә алмыйдыр ул. Җәй буе дачада яшәп, мин дә әтәч тавышына шулхәтле ияләшеп китәм: Казанга кайткач та, таң әтәче тавышын көтеп, йокыдан уянып бетә алмый алҗыйм. Кайчак шуңа аптырыйм: әтәч әллә йорт хуҗасын уятырга гына кычкыра микән? Аның тавышына нигә тавыклар уянмый? Күрше әтәче инде менә ничә сәгать буе кычкыра, тавыклардан хет бер мәртәбә «кыт» дигән тавыш та чыкмый. Менә шулай вәсвәсәләнеп ятам, тавыклар әтәчсез дә күкәй сала ала микән, дип тә уйлап куям. Бәләкәйрәк чагымда авыл хатыннарының берәрсе: «Тавыклар күкәйне азрак сала башлады әле», – дисә, аңа әтәчне алыштырырга тәкъдим итәләр иде. Әмма әтәч алыштырудан күкәйләр артуы нигәдер хәтердә калмаган. Мәсәлән, кошчылык фабрикаларында әтәч асрамыйлар бит, ә тавыклар күкәй сала. Әллә нинди ризыклар ашатып, аларны көненә берничә мәртәбә күкәй салырга мәҗбүр итәләр икән, дип тә ишеткәнем бар. Демографик ситуацияне яхшырту өчен, хатын-кызларга да теләсә нәрсә ашатып, тугыз ай эчендә ике мәртәбә бала табарга мәҗбүр итсәләр, ә? Бу дөньяда ниләр генә булмас, дисең, һава торышыннан алып җәмгыять тормышына кадәр аномаль күренешләргә тап була башладык. Әллә кешелек ычкына башлады инде, бүген трансгендерлар турында сөйләп, бөтен дөньяны шаулаталар. Күбрәк Америка мәш килә. Трансгендер үзенең хатын-кызмы, ирме икәнен психологик яктан тәгаен генә тоемлый алмаучы, ягъни ике җенес арасында буталып йөрүче була инде.

Американнар демократиянең зур «казанышы»ы булган бу нәстәкәйне башка илләргә дә көчләп такмакчылар. Бәлки, бу – күз буяу өчен генә башланган шау-шудыр, ә асылда мондый операциянең максаты башка илләрдә халык санын киметү түгел микән дип тә уйлыйм. Чөнки, белгечләр әйтүенчә, трансгендерлар гаилә кора, үрчи алмый. Аларның уртача гомер озынлыгы да 45 яшьтән артмый, дип укыганым бар. Ә инде 50 яшьтәгеләр озын гомерле санала, имеш.

Җенси тайпылышлар элек тә булган. Мәсәлән, «гермофродит» дигән сүз без балачакта ук колакка керә иде, «ирдәүкә» дигән сүз дә шактый еш ишетелде. Табигать хаталарына кешелек моңарчы әллә ни игътибар итмәгән, бәлки, «хата»лы кешеләр аз булгандыр. Мәсәлән, ишетүемчә, бер үк вакытта ир дә, хатын да була алганнар ике йөздән артмый икән. Грек Алласы Гермафродит исеме белән йөртелгән бу зәхмәт турында, белер-белмәс, әллә ни сөйләп тормыйм, аптыраганнар гына әйтү инде. Килячәктә кеше хокуклары саклау сылтавы белән һәм гражданнар үтенече буенча ирдән – хатын, хатыннан ир ясый башласалар, кешелек кая барып чыгар икән, дип куркам.

Әнә күрше әтәче инде ике сәгатькә якын бертуктамый кычкыра. Минем, таң әтәче кычкырганда, теләкләр кабул була икән, дип тә ишеткәнем бар. Бу – мөгаен, таң әтәче кычкыруның иртәнге намаз вакытына туры килүеннән чыккан сүздер. Ә мин моңа ышанам. Күрше әтәче тавышына кушылып, теләкләр телим. Раббым, безгә кеше булып калырга язсын, дөньялар тыныч булсын иде, дим.

15 август, иртәнге сәгать 4 туларга 15 минут

АШЛЫК КИЛЕШҮЕ ТИРӘСЕНДӘ БИЮЛӘР

Рәшит
ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

Үткән елның апрель ахырында без «Ватаным Татарстан»да «Бөтендөнья хаосын кем оештыра?» дигән язма биргәнбез. Махсус хәрби операция башланганнан соң, Россия һәм Украина ашлыгын, Белоруссия ашламасын экспортлауда кыенлыклар тугач, планетага глобаль ачлык янау турында шау-шу кубара башладылар. Бу шау-шуның нигезендә кытлык түгел, ә хаос оештырырга тырышу ятканлыгын дәлилләп, мондый юллар биргәнбез: «Кайчандыр бу өч илне үзенә берләштергән СССР ашлыкны да, башка азык-төлекне дә читкә сатмый, күпләп сатып ала, әмма ачлык юк иде. Хәзер ни өчен андый куркыныч туа? Кытлыкка ни сәбәп бар?» – дигәнбез һәм: «Ачлыкны махсус оештырырга тырышалар. Нииндер көчләргә планетада зур хаос һәм шок кирәк», – дигән нәтиҗәгә килгәнбез. Бәхәсләшмибез: без субъектив фикер әйтәбез, әмма аны объектив фактлар белән дәлиллибез.

Дөньяда ачлык өчен сәбәпләр юк, әмма ачыгучылар һәм ачтан үлүчеләр җитәрлек. Дөнья статистикасын ачабыз һәм карыйбыз: бүген 871 млн 981 меңнән артык кеше ачыга, бу юллар язылган сәгатькә – 16 август иртәсендә планетада 12 меңгә якын кеше ачтан үлде инде. Әмма 1 млрд 748 миллионнан артык адәм баласының авырлыгы тиешеннән артык, симезлектән интегүчеләр саны 842 миллионга якынаеп килә. Чүплеккә ташланган һәм исраф ителгән азык-төлек күләме исә йөзләгән миллион кешене туендырырга җитәрлек. Димәк, ачлык бар икән, ул – ресурсларның дөрес бүленмәве нәтиҗәсе генә. Ресурслар тирәсендә исә зур көрәш бара. Июль уртасында Россия туктаткан «ашлык килешүе» – шул көрәшнең бер тармагы. Рәсми белдерүләр белән чынбарлык арасында бик зур аерма бар анда. Мәсьәләнең асылы тышкы яктан болайрак күренә: Кара диңгез ашлык экспортлаучы иң зур ике дәүләтнең кан тамыры кебек. Статистикага ышансак, Россия ашлыгының 90 проценты, Украина икмәгенең шулай ук иң зур өлеше шул кан тамыры аша уза. Россиянең авыл хуҗалыгы министры Дмиртий Патрушев үткән авыл хуҗалыгы елында (ул ел 30 июньдә төгәлләнде) Россиянең 60 миллион тонна ашлык экспортлавын әйтә. Җыелган уңышның байтак өлеше (158 миллион тонна җыелган) читкә киткән, әмма эчке базарда кытлык булмады, киресенчә, ашлыкны куярга урын тапмадылар һәм аның бәясе төште. Быелгы уңыш кимрәк булачак, әмма экспортны кызулатырга кирәк, диләр, чөнки, бердән, үткән елгы запаслар күп, икенчедән, доллар кыйммәтләнү сәбәпле, экспорт зур табыш бирә. Кара диңгездәге конфликт нәтиҗәсендә ашлык бәясе артты да.

Ашлык килешүенең өзелүенә глобаль ике төбәк пошына: Көнбатыш дөньясы һәм Африка илләре. Көньяк Африка Республикасы Президенты Рамафосаның Путинга: «Без сиңа хәер сорарга килмәдек, «ашлык килешүе»н яңарт», – дигән сүзләрен искә төшерик әле. Рамафоса барлык Африка илләренең теләген әйтә, чөнки кара континент илләрен берләштерүче оешмаларда да җитәкче вазыйфалар башкара һәм аның сүзләре риясыз. Ә менә Көнбатышка килгәндә, алар «ашлык килешүе»н сүздә генә яклыйлар. Мәскәүнең июль демаршы Көнбатыш белән сәхнә арты килешүләре нәтиҗәсе түгелме икән әле? Искәртәм: автор үз фикерен генә белдерә. Көнбатыш башкалалары белән Мәскәү арасында яшерен консультацияләр бара ул үзе, әмма ул очрашуларда ниләр сөйләшенүе безгә мәгълүм түгел. Ләкин халыкка бик үк игълан ителми торган икенче бер нәрсә бар: үткән ел Евросоюз Украина ашлыгын һәм азык-төлеген үзләрендә сатуга тыю кертте һәм Көнчыгыш Европа илләре бүген дә ул эмбаргоны озайтуны таләп итәләр. Аларны берәү дә гаепләми. Украина ашлыгын Кара диңгез аша гына түгел, Польша аша озатып, Балтыйк портлары аша да сатып була. Әмма моңа поляклар ачыктан-ачык каршы чыга. Моның сәбәбе бик тирәндә түгел. Украина азык-төлеге сатылса, Евросоюзда бәяләр төшә. Евросоюз исә – үзе экспортлаучы. Америка белән Канада да – ашлык сатучы төп илләр. Үткән ел ашлык бәясе түбән булды. Көнбатыш илләренең фермерлары кесәсенә байтак сукты. Ничек уйлыйсыз: Украина ашлыгы экспортлансын өчен, Көнбатыш илләре ихлас җан атамы? Риторик сорау бу. Барлык экспортлаучы илләр дә дөнья базарында үз ашлыгын һәм кыйммәткә сатарга омтыла. Алар Украина гына түгел, Россия ашлыгы да сатылмасын дип телиләр. Һәм Мәскәүнең «ашлык килешүе»ннән чыгуын алар ике төрле файдалана: а) халыкара мәйданда, бигрәк тә Африка илләре алдында Россиянең имиджын төшерергә тырышалар, бәя күтәрелүнең төп сәбәпчесе – Мәскәү, дип күрсәтәләр, ә) базарда кыйммәткә үз ашлыкларын саталар.

Кара диңгездә эскалация, ягъни киеренкелек масштабын үстерү – асылда көнбатыш илләре мәнфәгате ул. Эш бит болайрак тора: килешүдән чыгуны игълан иткәч, Мәскәү икенче адымны да ясамый кала алмый. Украина портларына килүче теләсә кайсы ил корабына һөҗүм булачагын да әйтергә туры килә. Игълан иткәч, һөҗүм итмәсәң, җиңелүче буласың, һөҗүм итсәң, бер дә кирәкмәгән илләр белән конфликтка керергә туры килүе бар. Бер Израиль корабы, блокаданы узып, Одессага килде, дигән хәбәр таратылды күптән түгел генә. Чынмы, фейкмы икәнен без әйтә алмыйбыз, әмма Мәскәүгә Палау офшор дәүләте флагы астында йөзүче бер корабка ут ачып туктатырга һәм десант төшереп, аны тикшергәннән соң җибәрергә туры килде. Бу офшор флагы астында АКШ яисә Бөекбритания кораблары йөзә, диләр. Димәк, кораблар Украина портларына йөреп торалар. Бу – проблеманың кечкенә өлеше генә. Мәскәүнең диңгез хокукын (шундый кагыйдәләр җыелмасы яши) бозмыйча гына корабларны туктатырга мөмкинлеге бар. Мәсьәләне Киев көтелмәгәнчә катлауландырды: Россия портларына килүче теләсә кайсы ил корабына һөҗүм итәчәген белдерде һәм Россиянең бер хәрби корабы белән бер танкерын сафтан чыгарып, белдерүенең буш түгеллеген раслады. Россия Украина портларына ракета һөҗүмнәре белән җавап бирде бирүен, ләкин үз портлары да куркыныч астында.

Вазгыятьне коткару Әрдоган өстенә йөкләнде. Аның мондый уеннарда зур тәҗрибәсе, осталыгы бар. Соңгы көннәрдә ул Россияне һәм Путинны яклап, Көнбатышны гаепләп, белдерүләр ясый. Уйныймы, ихлас чыгыш ясыймы – бу очракта мөһим түгел. Мөһиме: Путин – Әрдоган очрашуы. Очрашуның нәтиҗәсе артык шөбһә тудырмый: ашлык килешүенә Россия әйләнеп кайтыр, бәлки, үзенә кайбер ташламалар да сорап алыр. Моңа Көнбатышта да шикләнмиләр.

Кремль, вазгыятьне катлауландырып, үз вазыйфасын үтәде (ашлыкка бәяләр күтәрелде), хәзер бонусларга өметләнә ала. Монда иң мөһиме – мизгелне кулдан ычкындырмау. Әрдоган исә, яңа «ашлык килешүе» Украина белән Россия арасында зур килешүнең беренче адымы була ала, дип ышандыра. Белмәссең, Әнкара басымы астында Көнбатыш Россиягә бонуслар вәгъдә итсә, төрек лидеры махсус хәрби операциянең уңышлы тәгәлләнүенә алып килүче «тынычлык күгәрчене» вазыйфасын да үтәмәсме? Мәскәүдә Пригожин фетнәсе масштабындагы катлаулану булмаса яисә нииндер бер зур техноген катастрофа оештырылмаса, Путин конфликт башланганнан соң беренче тапкыр НАТО иленә визит белән барыр дип өметләник. Бу аңа үзенең формада икәнен раслау өчен дә кирәк. Әрдоган килсә дә начар түгел, килешү генә булсын.

Зөһрә
САДЫЙКОВА

ТӘПИЛӘҮГӘ КАЛМАГАЕК

ТАКСИ ХЕЗМӘТЕН ҮЗГӘРЕШЛӘР КӨТӘ

Сентябрьдән Россиядә, шул исәптән Татарстанда да такси агрегаторлары өчен яңа кагыйдәләр кертеләчәк. Белгечләр, әлеге үзгәрешләр такси бәяләре артуга китерәчәк, дигән фикердә. Аеруча ерак араларга сәфәрләргә бәя ким дигәндә ике тапкыр артачак, дип фаразлый алар. Үзгәрешләрдән кемнәр ота, ә кемнәр оттырачак?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Нәрсә үзгәрәчәк?

Иң зур яңалык – сентябрьдән такси агрегаторларына лицензиясе булмаган машина йөртүчеләргә заказлар бирү тыелачак. Шулай итеп, машина йөртүчеләр, таксида пассажирлар ташу һәм багаж алу өчен, рәсми рөхсәт алырга һәм медицина тикшерүе узарга тиеш була. Әлеге вакытта лицензия нибары һәр бишенче такси йөртүчедә генә бар. Законны бозучыларны зур күләмдә штрафлар көтә. Икенчедән, таксига чыгучы автомобилистларга ОСАГОны кешеләр йөртү тарифы буенча эшләтергә туры киләчәк. Ә бу исә аларның акча янчыкларын шактый юкартачак. Моннан тыш, сентябрьдән лицензияне үзмәшгуль булган машина йөртүче дә ала алачак. Моңа кадәр бу мөмкинлек бары тик юридик затларга һәм эшмәкәрләргә генә бирелә иде. Шулай ук автомобиль хуҗасының таксопаркка да рәсми төстә урнашу мөмкинлеге саклана. Яңа кагыйдәләр кертелгәч, такси машиналары башкалардан аерылып торачак. Чөнки моннан соң алар ак һәм сары төстә генә булачак. Шунысын да әйтергә кирәк: федераль һәм төбәк нормалары 5 еллык күчеш чорын күзаллый.

– Әлеге үзгәрешләр бүген таксида эшләүче машина йөртүчеләрнең 90 процентына кагыла. Һәм барысы да яңа таләпләргә туры килеп бетмәячәк. Әйтик, бөтен кеше дә ак яки сары машинада йөрмәскә мөмкин. Шуңа күрә таксига чыгучыларның бер өлеше базардан китәргә мәҗбүр булачак. Аннан соң алар арасында пассажирлар ташуга өстәмә кәсеп кенә итеп карауучылар да шактый. Алар такси хезмәтеннән бөтенләй китәчәк, – ди «КОРП» җәмгыяте җитәкчесе Вероника Андриянова.

Нәрсәгә китерәчәк?

Даими рәвештә генә түгел, ара-тирә таксида йөрүчеләр дә соңгы ике-өч айда такси бәяләренең шактый өскә сикерүен сизми калмагандыр.

– Мин элек уңайлы һәм тиз булганы өчен такси хезмәтеннән еш файдалана идем. Тик май аеннан бәяләрнең артуын нык тойдым. Хәзер бик кирәк булганда гына такси чакырам, – ди Казанда яшәүче Гөлия Исламова.

Халык кына түгел, рәсми саннар да шуны ук сөйли. Әйтик, күптән түгел Росстат такси бәяләренең соңгы ун елда иң югары ноктасына менеп җитүен хәбәр итте. Мисал өчен, июньдә бер километр юл узу 32,53 сумнан исәпләнелә. Иң зур сикереш елның беренче яртысына туры килгән: бәяләр шунда ук 4,03 процентка арткан. 1 сентябрь алып килгән яңалыкларның да такси бәяләрен күтәрәчәгенә шик юк, дип фаразлый белгечләр.

Транспорт һәм юл төзелеше министры Фәрит Хәнифов, июльдә Татарстан Дәүләт Советында яңа законны караган вакытта, үзгәрешләр такси бәяләрен берникадәр күтәрәчәк, тик аннан соң тотрыклылык урнашачак, дип белдергән иде.

– Без таксида бер тапкыр йөрү кэшын (програма хәтере) анализлаган идек. Бу эшне 2017 елдан бирле алып барабыз. Бездә һәрвакыт такси бәяләре арта һәм кими торган периодлар бар. Казанга туристлар агыла башлагач, хаклар өскә сикерә, аннан соң тагын үз халәтенә кайта, – диде Фәрит Хәнифов.

Аның сүзләренчә, узган ел республикада 8 мең такси теркәлгән булган. Әлегә аларның 3,5 меңе генә калган.

Министр алга таба бәяләрнең тотрыклы булачагын әйтсә дә, такси йөртүчеләр аларның кисәк һәм күпкә артуын фаразлый.

– «Яндекс» бәяләрнең 20 процентка күтәрелүен әйтә, ләкин, минем уйлавымча, арту 50 процентка кадәр барып җитәчәк, – ди «Яндекс Такси» сервисы йөртүчесе Артем Кузьмин. – Чөнки сентябрьдә болай да такси бәяләре күтәрелә. Мәктәпләрдә, уку йортларында укулар башлана, юллар тыгызлана, урамнар «бөке»ләр белән тула. Моннан тыш, кайберәүләр такси хезмәтеннән китәчәк. Быел җәй бәяләр болай да артты, чөнки машиналар һәм аларга запас частьларның хаклары күтәрелде. Мин, бәлки, бу фикерне әйтергә дә тиеш түгелмендер, тик кайвакыт гаделсез бәяләр куела, дип саныйм. Кулланучы күзлегеннән караганда, бәяләр, чыннан да, бик югары. Аларга кыска гына ара узар өчен дә шактый акча чыгарып салырга туры килә.

Яңа кагыйдәләрне исә ул тыныч кабул иткән.

– Үзгәрешләр пассажирлар һәм машина йөртүчеләр өчен ниндидер уңайлыклар алып килә икән, уңай карыйм. Моңа кадәр шартлы рәвештә хөкем ителгәннәр дә таксига чыга ала иде, аннан соң аларга юллар ябылачак. Монысын уңай күренеш, дип уйлыйм. Такси – минем өстәмә эшем генә. Пассажирлар йөртүнең файдасы бар, әлбәттә. Тик сентябрьдән туктаячакмын, чөнки лицензия алуны кирәк дип санамыйм. ОСАГО, техник тикшерү узу да күп акча таләп итә. Машинага да махсус тасма ябыштырасы килми.

«Максим» такси сервисының матбугат үзәге җитәкчесе Павел Стенников фикеренчә, үзгәрешләр базардан легаль машина йөртүчеләрне дә кысрыклап чыгарырга мөмкин.

– Хәзерге вакытта заказларның 90 процентын үзмәшгульләр үз машиналарында башкара. Аларга яңа закон куйган шартларны үтәү җиңел булмаячак, – ди ул. – Әйтик, моннан соң таксида эшләү өчен машина йөртүчегә такси тарифы буенча ОСАГО узарга кирәк булачак. Хәзерге вакытта Казанда сервис белән хезмәттәшлек итүче 46 мең автомобиль йөртүченең 711ендә генә мондый төр полис бар. Чөнки иминият компанияләре пассажир ташу өчен файдаланыла торган машиналарны иминиятләштерүдән баш тарта. Аларның бәяләре дә берничә тапкыр артыграк.

Павел Стенников фикеренчә, күзен рәсми төстә бары тик 700 кеше генә эшли алачак. Калганнары «соры базар»га күчәчәк. Димәк, бу – бәяләр артуга тагын бер сәбәп дигән сүз.

Һәркемнең үзенеке

Районнардагы такси хезмәтен дә белештек. Тик бирелдә вазгыять бераз үзгәрәк. Пассажирларны йөртү мәсьәләсендә һәркем үзенә үзе хуҗа. Аларны контрольдә тотучы да, алар белән эшләүче рәсми оешмалар да юк. Кайберләре хәтта 1 сентябрьдән кертелә торган яңалыклардан хәбәрдар да түгел.

– Безгә беркемнең бернәрсә әйткәне юк. Башка такси йөртүчеләр белән дә бу турыда сөйләшкәнебез булмады, – диде төксе генә Азнакай шәһәре эчендә һәм аның авыллары арасында пассажирлар ташучы Альбина ханым. – Мин үземә үзем хуҗа. Машинама утырам да чыгып китәм. Без теге яки бу эшне вазгыятькә карап хәл итәбез. Бензин, ягулык арта икән, димәк, такси бәяләре дә күтәреләчәк. Районда такси бәяләренең узган елдан бирле артканы юк, бер чакрым юл узган өчен 20 сум алабыз. Башкортстанда – 22 сум. Багаж өчен, бөтен җирдәге кебек, өстәмә хак түләттерәбез. Пассажирның зур сумкасы бар икән, ул акчасын кызганмаска тиеш.

Буа районында пассажирлар йөртүче Максим үзгәрешләрне борчылып кабул иткән.

– Такси – хәзерге вакытта минем төп табыш чыганагым. Әгәр 1 сентябрьдән таләпләр чыннан да катгыйлана икән, бер көн дә эшләмәячәкмен. Шул кадәрле акча түгеп, таксист булып йөрү миңа кирәкме? Юк, әлбәттә, – диде ул. – Бәяләр болай да бик арзан. Шәһәр буенча 70 сум. Комиссияне дә алгач, кулга 62 сум кала. Ерак араларга йөрү генә хәлне бераз җиңеләйтә. Казан, Әлмәт, Чаллы, Ульяновск, Мәскәүгә барам. Шуңа күрә, әгәр лицензия алуны, ОСАГОны такси тарифы белән ясатуны таләп итсәләр, вахтага китәчәкмен.

Такси бәяләре нәрсәгә карап формалаша:



Бәяләр

2014 елда бер 1 км юл	**22,93 сум**
2021 елда	**25,69 сум**
2023 елда	**32,53 сум**

«Чек Индекс» сервисы мәгълүматлары буенча, быел беренче яртыеллыкта таксида йөрү уртача 435 сумга чыга.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ҮЗГӘРЕШ ҖИЛЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов

НӘРСӘ БУЛДЫ СИҢА, РУБЛЬ?

Гади итеп әйтсәк, теләсә кайсы валюта (доллар, евро, сум, юань) ул – товар. Алар белән дә сәүдә итәләр. Банк, биржа дигән сүзләр колакка ят түгелдер? Сорау зур, ә тәкъдим юк дәрәҗәсендә булса, «товар» бәясе, билгеле, күтәрелә. Һәм киресенчә дә булырга мөмкин.
Соңгы арада Россиянең экспорттан килгән кереме әллә ни түгел. Чикләүләр, нефть, газ бәясенең очсызлануы чорында яшәвебезне онытмыйк. Экспортерларның исәп-хисап эше дә хәзер сумда башкарыла. Компанияләр биржада сум сатып, аны тотрыкландырды. Әмма хәзер аларда бу валюта азайды, ә импорт мөмкинлекләре, киресенчә, артты. Импортерларга чит илләргә чыгу өчен валюта күбрәк кирәк, ә ил эчендә ул булмагач, доллар, евро, юань һәм башка валюталарның курсы үсә дигән сүз.
Сәбәпләрнең тагын берсе – бюджет дефициты. Чыгымнарның керемгә караганда бик күпкә артыграк булуы көн кебек ачык. Чагыштыру өчен: 2023 елның беренче яртыеллыгында гына да бюджет дефициты 2,6 трлн сумны тәшкил итте. Ә бит ул ел дәвамында 2,93 трлн сумнан артмаска тиеш. Димәк, бюджетка күбрәк акча җәлеп итүнең бер юлы – милли валюта курсын түбәнгә төшерү. Казнага кергән кайсы миллионнар яхшырак соң: 1 доллар – 70–80 сум яисә 1 доллар 100 сум булгандагысымы?

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

«Телевизор сатып алырга чабасы түгел»

Акчаның беркайчан да артык булган чагы юк әле. Шуңа да ил-көндәге икътисадый вазгыятькә, үзгәрешләргә бераү дә битараф кала алмый. Без әле кая барабыз? Татарстан Иҗтимагый палатасының финанс һәм икътисад мәсьәләләре буенча белгече **Фәнис ХӨСӘЕНОВ** белән шул хакта сөйләштек.

:: Фәнис Сәярович, сум белән ни булыр?
– Беренчедән, ни өчен Үзәк банк мондый адымга барды соң? Иң беренче чиратта, бу сумның көчсезләнүенә бәйле. Бер долларның 95–100 сум тирәсендә булуын искә төшерик. Үзәк банкның бу адымы сумның тотрыклануына китерергә тиеш. Һәрхәлдә, барысы да моңа өмет итә.

:: Ставка күтәрелгәннән соң, кертем, кредитлар нишләр?
– Аңлашыла инде: кертемнәр үсәчәк. Төп ставка 8,5 проценттан 12 процентка менгәнен искә төшерик. Еллык кертемнәр якынча 11,9 процентка кадәр артачак дип фаразлана. Бәлки, кайбер банклар 11,5 процент тәкъдим итәр. Кредитка килгәндә, билгеле, банклар аларның да ставкасын арттырачак. Элегрәк алган кредитлар үзгәрешсез калачак.

:: Җыйган акчаны нишләтергә мөмкин?
– Соңгы арада халыкның кереме уңай якка үзгәрде. Хезмәт хаклары артты. Димәк, ил халкы «кулланучы режимы»на күчте. Нигездә, безнең илдәге күпчелекне импорт товарлар тәшкил итә. Бәяләр кисәк артмасын өчен, йә булмаса аларны авызлыклау өчен генә булса да, Үзәк банк ставканы күтәрергә мәҗбүр булды. Бу очракта халык та акчасын пыран-заран китермичә, теләсә нәрсә сатып алуга түгел, ә туплау, кертем итеп саклауга тотачак. Бу аларга кызыклы булачак, чөнки, алдарак әйтүебезчә, кертем буенча процентлар үсте. Акчасын банкка салучылар барыбер булачак.

:: Ул-бу була калса, халык күпләп товар сатып алу ягына авыша. Товар җыя башларгамы инде?
– Әлбәттә, моны киңәш итмибез! Сум барыбер тотрыкланачак. Фаразларга ышансаң, ел азагына доллар уртача 93–95 сумнан артмаячак. Хәзер ыгы-зыгылы вакыт. Күпләп әйбер сатып ала башласалар, бәя артачак. Хәтерегездә булса, узган елның апрелендә дә шундый чор булып алды. Күпләр алтышар телевизор, бишәр суыткыч алды. Соңрак бу товарларга бәя тотрыклануын күзәттек. Шуңа күрә болай эшлисе түгел. Доллар үскән дип кенә, кесәдәге юклы-барлы акчаны чит ил валютасына алмаштырудан файда юк. Финанс базарында кискен үзгәрешләр булган чорда туктап көтеп тору – иң хәерлесе.

Машина базары

Бер җирдәге бәя үзгәреше икенче җирдәгесенә тәэсир итми калмый, билгеле. Чылбырлы реакция башланды дияргә була. Вазгыятьнең ни хәлдә булуын аңлар өчен, икътисадның башка өлкәләренә дә күз салыйк.

Машина сату салонында менеджер булып эшләүче Зөлфәт Галимов та төп ставка күтәрелгәннән соң машина базарында үзгәрешләр буласын инкарь итми. Әмма булган акчаны машина алуга тоту – хәзерге вазгыятьтә иң отышлы юлларның берсе, ди ул. Чөнки кулда «тимер ат» кала, аны исә соңрак сатып җибәрергә дә мөмкин. Хәтта зуррак бәягә!

– Соңгы ике айда бәяләр күтәрелә башлады. Хәтта көнләп түгел, сәгатьләп! Доллар бит минут саен үзгәреп тора, – ди менеджер. – Бәяләр тагын да күтәреләчәк, билгеле. Машина базарында гына түгел, автокредит, кулланучы кредиты, ипотека, дисеңме, үзгәреш җиле барысына да кагылачак.

Зөлфәт Галимов әйтүенчә, халык «пробег»лы машиналарга өстенлек бирә. Бу тенденция үзгәрешсез калачак, дигән фикердә ул. «Икенче урында – Россиядә җитештерелгән машиналар. «Лада», «Нива»лар үз урынын бирмәячәк. Аннан инде Кытай машиналары», – ди Зөлфәт.

– Машина алган кеше үз акчасын югалтмый. Бүген ала икән, ул аны иртәгә кыйммәткәрәк сата да ала. Автосалоннан чыккан машина бәясен югалта, дигән фикер бар иде элек. Әмма хәзер алай түгел, – ди менеджер. – Алган бәядән кыйбаткарак сату мөмкин. Хәтта йөрелгән, бәрелгән машиналарны да.

Халык өчен дәүләт программалары яңадан эшли башласа, кулай булыр иде, ди Зөлфәт Галимов.

Торак базары

Ипотека ставкалары турыдан-туры төп ставкага бәйле. Төп ставка үсә икән, коммерциячел кредитларның проценты да арта дигән сүз.

– Бу ставка озак вакытка исәпләнгән булса, ел азагына кадәр торак базарындагы ихтыяҗ бермә-бер кимеячәк, – дип уйлый «Этажи» компаниясендә риелтор булып эшләүче Сергей. – Кызыксыну якынча 20–25 процентка кадәр кимер дип саныйм. Әгәр дә мондый ставканың «гомер»е кыска булса, беренчел торак базары үзен иркен тотачак. Чөнки льготалы ипотека программалары гамәлдә кала. Дәүләт аларга ким дигәндә 2024 елның 1 июленә кадәр акча бүлеп бирә. Тик шунысы да бар: беренчел торакмы, икенчелме – алар үзара бәйләнештә. Яңа төзелеп килә торган фатирларга ставка менә дигән булып та, икенчел торакта хәлләр мөшкелрәк булса, ихтыяҗ кимү икесенә дә кагылачак.

Риелторлар, торак базарындагы ыгы-зыгы озакка сузылмыйча, берничә атнада тынар, дип тә фаразлый. Шуннан соң сатучылар бәяне төшермәс, ә сатып алучыларның бу суммага торак сатып алырга матди мөмкинлеге булмаячак.

– Кулында җыйган акчасы булып, элеккеге ставка буенча ипотека рәсмиләштереп өлгергән кешеләр фатир алып калырга ашыгачак, – ди Сергей.

«КОВИД»ЛЫ ЧОРДАН БАШЛАП ТӨП СТАВКА НИЧЕК ҮЗГӘРДЕ? (%)



Динә
ГЫЙЛАҖИЕВА

ОЧТЫ, ОЧТЫ...

РОССИЯДӘ ШӘХСИ МӘГЪЛҮМАТ ТАРАЛУ ОЧРАКЛАРЫ АРТКАН

Соңгы ике ел эчендә Россиядә шәхси мәгълүматларның теләсә кая таралу очраклары 40 тапкыр (!) арткан. Кая барсаң да, иң беренче эш итеп, шәхси мәгълүматларыңны алырга рөхсәт сорыйлар. Ризалык бирмәсәң, эшең пешми. Ышанып тапшырсаң, алар көннәрдән бер көнне әнә шулай теләсә кая таралып, үзеңә каршы эшли башлый. Бу очсыз-кырыйсыз чоңгылга эләкмәс өчен ни эшләргә? Шәхси мәгълүматны тараткан өчен нинди җаваплылык каралган?

depositphotos.com

Шәхси мәгълүматны законсыз тараткан өчен административ җаваплылыкка тартырга мөмкиннәр. Штраф күләме:

✓*гражданнар өчен.......................................**6000 сум***
✓*вазыйфаи затлар өчен.............................**20000 сум***
✓*оешмалар өчен..**100000 сум**га кадәр.*

Бу гамәл өчен җинаять җаваплылыгы да каралган. Шәхси мәгълүматны таратучыга ике елга кадәр ирегеннән мәхрүм ителү, әгәр җинаять үз вазыйфасыннан файдаланып кылынган булса, дүрт елга кадәр ирегеннән мәхрүм ителү куркынычы яный.

Казанда яшәүче Эльвира Зыятдинова көннәрдән бер көнне картасыннан ай саен күпмедер күләмдә акча югалып баруын күреп ала. Тикшерә башлагач, аның исеменә бер микрозаем оешмасында кредит рәсмиләштерелгәнлеге ачыкланган. Ул гына да түгел, кредитны алып, вакытында түләмәгән өчен Эльвираны инде судка бирергә өлгергәннәр. Баксаң, Эльвираның оешмага, дөресрәге, хәзер инде коллекторларга 17,5 мең сум акча кайтарасы бар икән.

– Мин әле дә шок хәлендә. Микрозаем оешмасыннан кредит алганда паспорт кына кирәк, дип ишеткәнем бар. Әмма паспортның үзеннән башка да кредит рәсмиләштерә алалар дип күз алдыма да китермим идем. Шәхси мәгълүматны теләсә кая чәчеп йөри торган кеше түгел мин. Моңа сак карыйм. Бөтен кешенеке кебек үк, Дәүләт хезмәтләре порталында мәгълүмат бар да, яратып йөри торган кибетләремә бонус картасы рәсмиләштергәндә паспорт номерын керткәнем истә. Хәзер бу мәгълүматның конкрет каян таралганын ачыклап бетереп тә булмый инде, – ди Эльвира.

Суд карарына шикаять белдергән, полициягә гариза язган. Шәфкать туташы булып эшләүче кыз бу эш буенча боз кузгалганны көтә. Бурычын да түләрсең, чынлыкта бер гөнаһың булмаган килеш кредит тарихының бозылуына гына борчыла ул.

Роскомнадзор идарәсеннән алынган мәгълүматка караганда, соңгы ике ел эчендә Россиядә шәхси мәгълүматларның теләсә кая таралу очраклары 40 тапкыр (!) арткан. Чагыштыру өчен: 2021 елда – илдә шундый дүрт очрак, 2022 елда 140 очрак теркәлгән. Быелның гыйнвар – июль аралыгында исә инде шундый 150 очрак теркәлергә өлгергән. Белгечләр әйтүенчә, бу әле – рәсми саннар гына, рәсми булмаган очракларны да исәпкә алсаң, чынлыкта вазгыять күпкә мөшкелрәк. Соңгы тапкыр шәхси мәгълүматлар август башында, танылган бер китап кибетеннән таралган.

Бу мәгълүматны аларга кемдер ышанып тапшырган, алар, үз чиратында, саклыйм дип ышандырган бит югыйсә. Көндәлек йөри торган кибетләрдә бонус карталары рәсмиләштергәндә дә аны-моны уйламыйсың, билгеле. Нинди мәгълүмат сорасалар, шуны әйтеп саласың. Белгечләр исә соңгы арада мәгълүматларның күбрәк төрле банклардан, без яратып өлгергән маркетплейслардан таралуын искәртә. Банк картасы беркетелгән, аның турында тулы мәгълүмат кертелгән һәрбер чыганак куркыныч тудыра, кыскасы. Ышанычлы дип саналган СДЭК, «Россия почтасы», «ДНС» кебек зур оешмаларда да шәхси мәгълүмат таралу очраклары әледән-әле күзәтелеп тора. Шул ук вакытта, гаепләләрне эзләгәнче, үзебезгә дә саграк булырга кирәк, билгеле.

Татарстан Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының хокукый тәэмин итү бүлеге җитәкчесе Тимур Ашуралиев фикеренчә, бүген олыларны гына түгел, балаларны да шәхси мәгълүматларны сакларга өйрәтергә кирәк.

– Бүген балаларның да социаль челтәрләрдә үз сәхифәсе бар. Шуңа күрә аңа иң беренче чиратта мошенниклар «вата» алмаслык итеп ышанычлы пароль куярга кирәк. Сиңнән нәрсәдер эшләвеңне сораган сәер смс-хәбәрләргә дә җавап бирергә ярамый. Социаль челтәргә үзең турында артык күп мәгълүмат куярга да ярамый. Алар ярдәмендә мошенник корбанын яхшылап өйрәнәчәк, аның ниләр белән кызыксынуын, ниләр яратуын белеп торачак. Шулар ярдәмендә алар соңыннан кешене куркытырга, котыртырга, янарга, берәр нәрсә рәсмиләштерергә мөмкин. Таныш булмаган кеше белән язышкан смсларны да бетереп бармыйча, сакларга кирәк. Таныш булмаган кеше сәер смслар язса, бала бу хакта кичекмәстән ата-анасына хәбәр итәргә тиеш, – ди белгеч. – Таныш булмаган сылтамалар аша күчү дә куркыныч. Мошенниклар кулланган сайтларның адресы язылган юлда, гадәттә, танып булмый торган сәер символлар була. Аларын әнә шуннан чамалап була.

Белгеч фикере

«Дәлилләү кыен»

Шәхси мәгълүматның таралуы аркасында, кеше көндәлексез хәлгә тарырга, хәтта җинаять корбаны да булырга мөмкин бит әле. Ул очракта ни эшләргә?

Әлеге сорау белән «ВТ» юристы **Булат ЗАКИРОВ**ка мөрәҗәгать иттек.

– Теге яки бу хезмәтне күрсәтер алдыннан кешедән шәхси мәгълүматларын бирүен сорасалар, ул аны бирүдән баш тарта аламы? Андый чакта аңа хезмәт күрсәтүдән баш тарта алалармы?

– Шәхси мәгълүмат бирү – гражданның бурычы түгел, ә хокукы. Әмма, «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль законның 18 нче маддәсендә билгеләнгәнчә, әгәр федераль закон нигезендә шәхси мәгълүмат бирү һәм (яки) операторның шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык алуы мәҗбүри булса, оператор шәхси мәгълүмат бирүдән баш тартуның юридик нәтиҗәләрен аңлатырга тиеш. Мәсәлән, әгәр SIM-карта сатып алганда кеше үзенең паспорт мәгълүматларын бирүдән баш тартса, кагыйдә буларак, аңа хезмәт күрсәтүдән баш тартачаклар. Шул ук вакытта оператор шәхси мәгълүматны эшкәртүгә ризалыкны күрсәтелгән максатларда гына куллана ала.

– Шәхси мәгълүматның намуссыз кешеләр кулына эләгүе аркасында, кешегә кредит рәсмиләштереп куйганнар, ди. Бу очракта гаделлек урнаштырып буламы? Кемне җавапка тартырга?

– Шәхси мәгълүматны таратучыны җавапка тартып була. Моны дәлилләү генә кыенрак. Кешегә моңа кадәр беркайчан мөрәҗәгать итмәгән оешмалардан шалтыраталар, ди. Бу очракта аларга кемдер шәхси мәгълүмат таратканны ничек исбатларга? «Минем номерны кем бирде?» – дип сорасагыз да, аңа дөрес җавап бирүче булмаячак, билгеле. Сезгә шалтыраткан яки шул ук кеше исеменә кредит рәсмиләштергән оешмага рәсми сорау юлларга була. Әмма алардан рәсми кәгазь ярдәмендә дә анык җавап алуыгыз икеле. Роскомнадзор, Прокуратура, полициягә гариза язарга мөмкин. Бу ысул өметлерәк әле. Ник дигәндә, алар тикшерү башлап, закон бозу очрагы барлыгын ачыкласа, ул дәлил булып барачак.

Шәхси мәгълүмат таралмасын өчен, нинди кагыйдәләрне истә тотарга?

«Ростелеком» оешмасының программа куркынычсызлыгы өчен җаваплы белгече Данил Черновтан 7 киңәш

✓Фәлән көнгә кадәр акциядә катнашып калырга чакырган смс-хәбәрләрне, андагы сылтамаларны читләп үтегез. Ул хәбәр исеме билгеле кибеттән килгән булса да, ышанмагыз.

✓Телефон, компьютер, ноутбукка ышанычсыз чыганаклардан программалар йөкләтергә дә ярамый.

✓Вокзал, аэропорт, эре сәүдә үзәкләрендәге бушлай вай-файга да тоташырга киңәш итмәс идем. Алар аша кешенең нинди сайтларга керүен, электрон почта адресын, хәтта кирәкле логин-парольләренә кадәр бик җайлы табып була.

✓Телефондагы үзгәрешләргә дә игътибарлы булыгыз. Электрон китап уку өчен кирәкле кушымта сездән геолокация күрсәтүне сораса, шикләнергә җирлек бар.

✓Телефонга, кушымталарга төрле-төрле символлардан торган катлаулы парольләр уйлап табыгыз. Ул 8 символдан да ким булмасын. Анда сезгә кагылышлы бер генә шәхси мәгълүмат та булмаска тиеш. Бер үк парольне берничә җирдә кулланы да тыела.

✓Телефонга, компьютерыгызга антивирус программасы урнаштырыгыз.

✓Шәхси мәгълүмат тапшыру турында документ имзалаганда, эчтәлеген яхшылап укыгыз. Күпләр аны стандарт документ дип уйлап, укып тормыйча да кул куя. Юкса андагы кирәкмәгән бер пункт аркасында үзең турында мәгълүматны анда-монда таратуларына үз кулларың белән ризалык биреп куюың бар.

21 август | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 Утренняя программа «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «СИҢА КАЙТАМ». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «СВАТЬИ». Телесериал 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «АННА ГЕРМАН». Телесериал (татар телендә) 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Акыл батл» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Болгар радиосы» концерты 16+
18.00 «Гаилә учагы» 16+
19.00, 00.50 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
00.00 «Соотечественники». Альберт Суфианов. Я спасаю людей 16+
00.25 «Каравай» 6+
01.15 «Кичке аш» 16+
02.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Аулак өй» 6+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05 «Нур сибелгәндә». Татарстанның халык артисты Дания Нуруллина турында телеочерк 16+
15.30, 03.05 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30 «Адымнар» 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
19.30 «Калеб» 6+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30, 02.40 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
00.40 «Ватандашлар» 16+
03.30 «Йөрәктән – йөрәккә». Татарстанның халык артисты Резеда Шәрәфиева турында телеочерк 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.30 Информационный канал 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 К 50-летию легендарного фильма. «СЕМНАДЦАТЬ МГНОВЕНИЙ ВЕСНЫ». Многосерийный фильм 12+
23.15 «Большая игра» 16+
00.15 «Вызов». О фильме, покорившем космос 12+
00.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
01.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
01.50 ПОДКАСТ.ЛАБ «Неформат» 16+
02.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «АстроУмные» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «АстроУмные» 16+
03.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
03.50 ПОДКАСТ.ЛАБ «Гори огнем» 16+
04.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Сергей Безруков, Светлана Ходченкова, Александр Устюгов, Дарья Урсуляк, Илья Ильиных, Мария Андреева, Андрей Мерзликин, Александр Горбатов, Ирина Пегова, Евгений Ткачук. «ГОДУНОВ» 16+
16.30 «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Карина Андоленко, Илья Носков, Роман Маякин, Лариса Удовиченко и Михаил Жигалов. «СПАССКАЯ» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Анна Ковальчук в детективном телесериале «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.55 Ярослав Бойко, Анатолий Васильев, Раиса Рязанова, Дарья Повереннова, Илья Соколовский. «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 «Звёзды без правил» 12+
06.30 «Всё о главном» 12+
07.00, 09.30, 12.50 Новости
07.05, 16.25, 19.00, 21.30, 23.45 Все на Матч! Прямой эфир
09.35, 12.30, 01.35 Специальный репортаж 12+
09.55 Бокс. Чемпионат России. Прямая трансляция из Хабаровска
12.55 «Есть тема!» Прямой эфир
14.25 Регби. PARI Чемпионат России. «Химик» (Дзержинск) – «Металлург» (Новокузнецк). Прямая трансляция
16.55 Футбол. МЕЛБЕТ-Первая Лига. «КАМАЗ» (Набережные Челны) – «Арсенал» (Тула). Прямая трансляция
19.25 Футбол. Чемпионат Италии. «Торино» – «Кальяри». Прямая трансляция
21.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Болонья» – «Милан». Прямая трансляция
00.35 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 6+
01.55 Футбол. Чемпионат Бразилии. «Гояс» – «Атлетико Паранаэнсе». Прямая трансляция
04.00 Регби. PARI Чемпионат России. «Красный Яр» (Красноярск) – «Локомотив-Пенза» 12+

НТВ

04.40 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.20 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 Премьера. Сериал «ЗИМОРОДОК» (Турция) (S) 16+
20.00 Дмитрий Лавров, Ольга Павловец, Виталий Гудков в остросюжетном сериале «АНОНИМНЫЙ ДЕТЕКТИВ» (S) 16+
23.40 Премьера. «Путь бойца» 18+
01.00 Боевик «БРАТАНЫ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.35 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.00 «Давай разведёмся!» 16+
09.00 «Тест на отцовство» 16+
11.15 «Понять. Простить» 16+
12.30 «Порча». «Запах костра» 16+
13.00 «Знахарка» 16+
13.35 «Верну любимого» 16+
14.10 «Голоса ушедших душ» 16+
14.45 «БАБОЧКИ И ПТИЦЫ» 16+
19.00 «НЕЧАЯННАЯ ЛЮБОВЬ» 16+
23.20 «Понять. Простить» 16+
00.35 «Порча» 16+
01.05 «Знахарка» 16+
01.40 «Верну любимого» 16+
02.05 «Голоса ушедших душ» 16+
02.30 «ПОЗДНИЙ СРОК». 5-я – 8-я серии 16+
05.40 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.25 «ФЕЙЕРВЕРК» 12+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
11.00, 01.20 «НАЙТИ И ОБЕЗВРЕДИТЬ» 16+
13.25, 15.05, 17.15 «БЕЛАЯ СТРЕЛА. ВОЗМЕЗДИЕ». Телесериал. 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «Курская битва». Документальный сериал. «Стальная оборона Василевского». Премьера! 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам». Премьера! 16+
20.10 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Документальный сериал. «История «Шпионского моста» 12+
22.45 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.15 «ЗА ОБЛАКАМИ – НЕБО» 12+
02.50 «Калашников». Документальный фильм 12+
03.15 «Москва фронту». Документальный сериал 16+
03.35 «БЕЛАЯ СТРЕЛА. ВОЗМЕЗДИЕ». Телесериал. 1-я и 2-я серии 16+

22 август | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 Утренняя программа «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «СИҢА КАЙТАМ». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «СВАТЬИ». Телесериал 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 16+
11.15 «Память сердца» 16+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «АННА ГЕРМАН». Телесериал (татар телендә) 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Казаннан – Казанга» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Каравай». Узбеки 6+
00.50 «Соотечественники». Рафаэль Мустафин. Не копите в сердце зло 16+
01.15 «Кичке аш» 16+
02.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Аулак өй» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.250, 23.10, 04.20 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30 «Заман көзгесе» 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Нәсыйхәт» 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате» 16+
15.30, 03.05 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30 «Таяну ноктасы» 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Халкым минем» 12+
20.30, 02.40 «Таяну ноктасы» 16+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
03.30 «Йөрәктән – йөрәккә». ТАССРның халык артисты Хәким Сәлимҗанов турында телеочерк 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.30 Информационный канал 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «СЕМНАДЦАТЬ МГНОВЕНИЙ ВЕСНЫ». Многосерийный фильм 12+
23.15 «Большая игра» 16+
00.15 «Вызов». О фильме, покорившем космос 12+
00.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Письма» 16+
01.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «50 мгновений весны» 16+
01.50 ПОДКАСТ.ЛАБ «Кот Шрёдингера» 16+
02.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
03.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
03.50 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
04.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Повара на колесах» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу. 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Сергей Безруков, Светлана Ходченкова, Александр Устюгов, Дарья Урсуляк, Илья Ильиных, Мария Андреева, Андрей Мерзликин, Александр Горбатов, Ирина Пегова, Евгений Ткачук. «ГОДУНОВ» 16+
16.30 «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Карина Андоленко, Илья Носков, Роман Маякин, Лариса Удовиченко, Михаил Жигалов. «СПАССКАЯ» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Анна Ковальчук в детективном телесериале «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.55 Ярослав Бойко, Анатолий Васильев. «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.25 «Звёзды без правил» 12+
06.30 «Наши иностранцы» 12+
07.00, 09.30, 12.50, 14.55 Новости
07.05, 15.30, 18.30, 21.00, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.35, 12.30 Специальный репортаж 12+
09.55 Бокс. Чемпионат России. Прямая трансляция из Хабаровска
12.55 «Есть тема!» Прямой эфир
15.00 «География спорта. Грозный» 12+
16.25 Футбол. FONBET Кубок России. «Сахалинец» (Москва) – «Леон Сатурн» (Раменское). Прямая трансляция
18.55 Футбол. FONBET Кубок России. «Текстильщик» (Иваново) – «Амкал» (Москва). Прямая трансляция
21.45 Футбол. Лига чемпионов. Раунд плей-офф. Прямая трансляция
00.55 Футбол. Лига чемпионов. Раунд плей-офф 6+
02.55 Новости 0+
03.00 Автоспорт. Российская Дрифт серия. Гран-при 2023. Трансляция из Красноярска 6+
04.00 Регби. PARI Чемпионат России. «ВВА-Подмосковье» (Монино) – «Енисей-СТМ» (Красноярск) 12+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.20 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 Премьера. Сериал «ЗИМОРОДОК» (Турция) (S) 16+
20.00 Остросюжетный сериал «АНОНИМНЫЙ ДЕТЕКТИВ» (S) 16+
23.40 Премьера. «Путь бойца» 18+
01.10 Боевик «БРАТАНЫ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.20 «Давай разведёмся!» 16+
09.20 «Тест на отцовство» 16+
11.35 «Понять. Простить» 16+
12.50 «Порча». «Позор рода» 16+
13.20 «Знахарка» 16+
13.55 «Верну любимого» 16+
14.30 «Голоса ушедших душ» 16+
15.05 «БАРХАТНЫЙ СЕЗОН» 16+
19.00 «КАК МЫ ЛЮБИЛИ ДРУГ ДРУГА» 16+
23.20 «Понять. Простить» 16+
00.35 «Порча» 16+
01.05 «Знахарка» 16+
01.40 «Верну любимого» 16+
02.05 «Голоса ушедших душ» 16+
02.30 «СЕМЕЙНЫЙ ПОРТРЕТ» 16+
05.30 «6 кадров» 16+
05.40 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «БЕЛАЯ СТРЕЛА. ВОЗМЕЗДИЕ». Телесериал. 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
11.00 «РОДНАЯ КРОВЬ» 12+
13.25, 15.05, 17.15 «БЕЛАЯ СТРЕЛА. ВОЗМЕЗДИЕ». Телесериал. 5-я – 8-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «Курская битва». Документальный сериал. «Рокоссовский против Моделя». Премьера! 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам». Премьера! 16+
20.10 «Улика из прошлого» 16+
22.45 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.15 «Оружие Победы. Щит и меч Красной армии. У стен Сталинграда». Документальный фильм 16+
00.10 «Путь к Победе». Документальный фильм 16+
01.05 «ЗА ОБЛАКАМИ – НЕБО» 12+
02.45 «Выбор Филби». Документальный фильм 12+
03.15 «Москва фронту». Документальный сериал 16+
03.35 «БЕЛАЯ СТРЕЛА. ВОЗМЕЗДИЕ». Телесериал. 5-я и 6-я серии 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Мәгариф системасын үстерүдәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы **Кульбеда** Валентина Васильевна, мәгариф системасын үстерүдәге казанышлары һәм югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүләре өчен «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Н.И. Лобачевский исемендәге Математика һәм механика институты математика бүлекчәсенең алгебра һәм математик логика кафедрасы мөдире **Арсланов** Марат Мирза улы, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Лев Толстой мирасын өйрәнү буенча фәнни-белем бирү үзәге әйдәүче фәнни хезмәткәре **Бакиров** Марсель Хәернас улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Мәгариф системасын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең «Н.И. Лобачевский исемендәге лицей» гомуми белем бирү мәктәп-интернаты укытучысы **Михайлин** Сергей Иванович **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Мәгариф өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Лениногорск шәһәренең 12 номерлы лицее» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе концертмейстеры **Вәлиуллова** Гүзәл Исхак кызы, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәренең 2 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең технология укытучысы **Выжленкова** Ольга Владимировна, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Иске Шәйморза урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең туган (татар) тел укытучысы **Ибәтова** Зөмәрә Әнвәрша кызы, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенең оештыру-кадрлар бүлеге баш белгече **Моталапова** Лилия Әлхәт кызы, «Казан төзелеш көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры **Проснев** Александр Владимирович, «Казан педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директорының укыту-производство практикасы буенча урынбасары **Рамазанова** Гүзәл Илшат кызы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының мәктәпкәчә белем бирү бүлеге башлыгы **Хисамиева** Йолдыз Шамил кызы, «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Лениногорск филиалы директоры **Шәмсетдинов** Рәсим Әдһәм улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Казан шәһәре Идел буе районының «52 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең физика укытучысы **Афанасьева** Фәридә Хәлиулла кызына, Казан шәһәре Идел буе районының «22 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе директоры **Габдрахманов** Илгиз Вакыйф улына, Казан шәһәре Идел буе районының «35 номерлы лицей – «Галактика» укыту-белем бирү үзәге» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең инглиз теле укытучысы **Галиева** Гөлшат Камил кызына, Казан шәһәре Киров районының «101 номерлы катнаш төрдәге балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе мөдире **Галиева** Лилия Рәмзил кызына, Казан шәһәре Киров районының «13 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе директоры **Гыйрфанова** Луиза Илһам кызына, Казан шәһәре Идел буе районының «Мәктәптән тыш эш үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең өстәмә белем бирү педагогы **Ибәтова** Роза Нургат кызына, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Урманай авылы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы **Ихсанова** Эльвира Таһир кызына, Казан шәһәре Идел буе районының «6 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең физик культура укытучысы **Кокуркина** Любовь Семеновнага, Казан шәһәре Идел буе районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 48 номерлы урта гомуми белем бирү татар-рус мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Курдибан** Ольга Борисовнага, Казан шәһәре Киров районының «1 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең баян, аккордеон классы буенча укытучысы **Настаушев** Александр Михайловичка, «Казан шәһәре Идел буе районының балалар йорты» ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен дәүләт бюджет учреждениесе директоры **Самойлова** Марина Ростиславовнага, Казан шәһәре Вахитов районының «131 номерлы лицее» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең химия укытучысы **Сафонова** Әлфия Рөстәм кызына, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «1 номерлы лицее» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Семенова** Татьяна Анатольевнага, Казан шәһәре Мәскәү районының «Илһам Шакиров исемендәге 32 номерлы татар балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең тынлы уен кораллары укытучысы **Хисамов** Әхмәт Абдурахман улына, Казан шәһәре Идел буе районының «242 номерлы катнаш төрдәге балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең музыкаль җитәкчесе **Шмелева** Алла Алексеевнага, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «8 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Әюпова** Рубәба Юныс кызына, Казан шәһәре Идел буе районының «139 номерлы гимназия – Мәгариф үзәге» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең биология укытучысы **Якупова** Венера Фәрит кызына **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

АЛДАН ӘЗЕРЛӘНӘСЕ

Бер көнне укучыбыздан түбәндәге эчтәлектәге хат алдык. «Җәй буе салкын тиеп, йөткереп авырдым, көзгә керергә дә куркыта. Иммунитетны ничек күтәрергә? Нинди анализлар бирергә икән?» – дип киңәш сораган ул.

Әлеге сорауны Казан шәһәренең 3 номерлы шәһәр хастаханәсе табиб-терапевты, гирудотерапевт Гөлия ГЫЙМАДИЕВАга бирдек.

➤Иммунитет – организмның төрле авыруларга каршы тора алучанлыгы. Ул безнең организмның бөтенлеген саклауда бик зур роль уйный. Иммунитет карында чакта ук формалаша. Ул нык булсын өчен, иң беренче чиратта, дөрес тукланырга, йокы туйганчы йокларга, даими рәвештә физик күнегүләр ясарга, ешрак саф һавада йөрергә кирәк. Физик кына түгел, рухи сәламәтлек тә бик мөһим. Организмга нинди витамин, файдалы матдәләр җитмәвен дә даими рәвештә контрольдә тотарга кирәк.

➤Йоклаганда организм яңара, яңадан тугандай була. Иммунитетның ныклыгы да турыдан-туры биоритмнарның саклануына бәйле. Шуңа күрә даими рәвештә йокысын туйдырмый яшәгән кеше ялкынсынуларга да тизрәк бирешә. Иммунитет нык булсын өчен, кичке сәгать унга кадәр йокларга ятарга, бүлмәне яхшылап җилләтергә, яктылык төшми торган караңгы бүлмәдә йокларга кирәк. Йоклар алдыннан 200–400 мг магний эчү дә файдалы. Магнийлы ванна керү дә киңәш ителә. 500 грамм тозны суда эретергә дә бернечә аш кашыгы сода кушарга кирәк. Магнийлы ванна керер алдыннан 1 стакан су эчәргә киңәш ителә. Балаларның табан асларын магний мае белән массажлау да яхшы.

➤Иммунитетның ныклыгы 70–80 процент очракта эчәклекнең торышына бәйле. Ул иң зур иммун әгъза санала. Аның гомуми озынлыгы – 7–9 метр. Микрофлорасы чиста булган эчәклек организмны төрле инфекциялардән саклый. Ул организмнарны токсиннардан да арындыра. Чипсы, фастфуд, камыр ризыклары ашау, рационда клетчатка аз булу, составында буягычлар, шикәр күп булган ризыклар эчәклеккә зур зыян сала. Көндәлек туклануда глютенлы ризыкларны (он, токмач, камыр ризыклары һ.б.) да чикләргә кирәк. Алар урынына аксымга (ит, йомырка, кәҗә сөте, балык), витамин, минералларга, майларга бай ризыкларга, яшелчә, җиләк-җимешкә өстенлек бирү әйбәт. Ашказаны яхшы эшләгән кеше суган, сарымсак белән дуслашып та иммунитетын ныгыта ала.

➤Иммунитет нык булсын өчен, көн саен С витамины эчү дә хәерле. Балалар өчен аның күләме 100–250 миллиграммнан да артмаска тиеш. Өлкәннәргә исә көнгә ике тапкыр 500 мг күләмендә эчәргә киңәш ителә.

➤Ялкынсыну – организмның реакциясе. Шуңа күрә аның ни дәрәҗәдә нык икәнен белү өчен, иң беренче чиратта организмда ялкынсыну бармы-юкмы икәнне ачыкларга кирәк. Моның өчен гомуми кан анализы тапшырып, ферритин, СРБ, СОЭ, фибриноген, холестерин күләмен тикшертергә кирәк.

➤Бүген күпләр иммунитетны БАДлар ярдәмендә күтәрергә тырыша. Аларны хуплаучылар да, тәнкыйтьләүчеләр дә шактый. Шәхсән үзем моңа уңай карыйм. Организмга булышырга кирәк. Әгәр без бернинди радиация, телефоннар булмаган, экологик яктан чип-чиста җирдә яшәп, тулысынча табигый ризыклар белән генә тукланып торсак, БАДларның кирәге юк дип өздереп әйтер идек. Әмма бүгенге тормышыбыз моның нәкъ киресен дәлилли. Әйтик, D витамины да организмга җәй көне генә түгел, ел әйләнәсе кереп торырга тиеш. Кеше хәтта диңгез буенда да кирәкле күләмдә D витамины җыеп бетерә алмый. Шуңа күрә бу очракта БАДларсыз булмый. Әмма аларны үз белдегең белән түгел, махсус анализлар тапшырып, табиб белән киңәшләшкәннән соң гына эчәргә ярый. Чама хисен югалтырга ярамый.

shutterstock.com

ГӨЛИЯ ГЫЙМАДИЕВАДАН ИММУНИТЕТНЫ НЫГЫТУ ӨЧЕН КИҢӘШЛӘР

✓Сары мәтрүшкә төнәтмәсе иммунитетны ныгыта. Моннан тыш ул тынычландыра, организмдагы ялкынсынуны киметә, кан әйләнешен дә яхшырта. Аны ясау өчен 5 грамм сары мәтрүшкәгә 200 мл кайнар су салып төнәтергә кирәк. Шуны көнгә ике тапкыр ярты стакан күләмендә эчәсе. Әлеге төнәтмәне йоклар алдыннан эчсәң дә файдалы. Аны йөкле, бала имезгән хатын-кызларга эчү киңәш ителми.

✓Тешләрне кокос мае белән чайкау да файдалы. Аны шундук төкереп ташларга ашыкмагыз. Биш минут дәвамында авызны, тамакны кокос мае белән чайкап торуның шифасы да әйтеп бетергесез зур.

✓Ромашка да иммунитетны ныгытырга ярдәм итә. Ул ялкынсынуларны бетерә. Кан әйләнешен яхшырта, авыртуны баса. Аның төнәтмәсен ясау өчен, 5 грамм ромашкага 1 стакан кайнар су салып, 10 минут көтәргә кирәк. Шуны 0,5 стакан күләмендә йокларга бер сәгать кала эчәргә.

✓Ак чыршы согы да шифалы. 150 мл җылымса суга 25–35 тамчы ак чыршы согы салып, көнгә бер тапкыр эчәргә кирәк. Бер искәрмә бар: аны ун яше тулмаган балаларга эчәргә ярамый.

✓1–2 канәфер бөртеген чәйнәү дә иммунитетны ныгытуга зур өлеш кертә. 1 чәй кашыгы канәфер яфрагын кайнар суда төнәтеп эчәргә дә мөмкин.

Табигать даруханәсе

Керән шифасы

1 Кан басымын көйли. Моның өчен 200 г уылган керәнгә 3 л кайнап суынган су кушып, 15 минут кайнатыгыз. Иртәнгә кадәр суытыгыз. Иртән исә сөзеп, суыткычка куегыз. Көнгә өч тапкыр, ашар алдыннан 100 г эчәргә кирәк. Бер ай тәнәфестән соң дәвалану курсы кабатлана.

2 Аннан ясалган төнәтмә бик күп авырулардан дәва. Аның өчен керән тамырын казып алып, щетка белән яхшылап юарга да вак тишекле угычтан чыгарып, согы белән бергә шешәгә салып куярга. Ул шешәнең яртысы кадәр булырга тиеш. Өстенә аракы салыгыз. 10 көннән соң төнәтмә әзер. Ул ангина вакытында булыша. 1 аш кашыгы төнәтмә белән тамакны чайкарга һәм йотарга кирәк. Грипп вакытында төнәтмә белән ингаляция ясарга мөмкин.

3 Цистит, уретрит борчыса, 1 аш кашыгы уылган керәнгә 1 стакан кайнар су коеп, 5 минут төнәтегез. Көн саен 3–4 чынаяк эчәргә кирәк.

4 Трахеит, бронхит вакытында 1 аш кашыгы уылган керән тамырына 3 аш кашыгы бал кушып төнәтәләр.

Көненә 5 мәртәбә 1 чәй кашыгы белән кабып куярга кирәк. Масса авызда эреп китәргә тиеш.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

Үзем сынадым

Буынга файдалы

Буыннар авыртудан интегәм. Соңгы арада түбәндәге компрессның файдасын күрәм. Башта бер аш кашыгы балга бер аш кашыгы вак тоз салып, яхшылап болгатырга кирәк. Катнашманы җитен яки киҗе-мамык тукыма өстенә куеп, авырткан буын өстенә ябам да җылы итеп төрәм. Компрессны кичтән куеп, иртән генә алаcы. Аны авырту басылганчы һәр көн куям.

Тәнзилә ВӘЛИЕВА. Казан

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

СОҢЛАМАСКА

dreamstime.com

Августның соңгы ункөнлеге – гадәттән тыш мәшәкатьле чор. Җәй белән көз тоташкан мәлдә, бәрәңгеләр алынганчы, кайбер эшләрне төгәлләргә кирәк. Чөнки өсте-өстенә өелгән эшнең уңышны исраф итүгә китерүе бар. Хәзер соңга калмый нәрсәләрне эшләп куярга соң?

● Җимешләре җыелган агач, куакларны хәзер фосфор һәм калий белән тукландыру яхшы. Бу киләсе елда яңа үрентеләр булдыру өчен кирәк. Ә менә азотлы ашламалар кертә күрмәгез, чөнки куакларның, тизрәк үсә башлау сәбәпле, кышны чыга алмаулары бар.

● Чия белән слива агачының янындагы яшь үсентеләрен кисеп ташлагыз, чөнки алар агачның көчен генә алып тора. Август ахырында җимеш бирә торган агачларның өскә киткән ботакларын бераз кыркып куйсаң да ярый.

● Алманы өлгереп бетәргә 2–3 көн кала алдан җыеп куйсаң яхшырак, ул тартмаларда өлгереп бетәчәк. Коела башласа, аны җыюны кичектермәгез. Җыйганнан соң яхшылап карагыз: сәламәт булганнарын куллану өчен калдырып, авыру билгеләре булганнарын яндырсаң яхшы. Авыру җимешләрне компост өчен куллану андагы авыруларның таралуына гына сәбәпче булачак.

● Агачларның, уңыш күп булып, ботаклары асылынып төшсә, алар өчен күтәртмә әзерләгез. Ботакның күтәртмә өстенә куела торган өлешенә йомшак материал кую аның кайрысына зыян килүдән саклый.

● Куранның янга киткән ботакларының 40 сантиметрдан арткан өлешен кисәргә кирәк. Моны көче ботак үстерүгә түгел, ә җиләк өлгертү өчен китсен өчен шулай эшлиләр. Уңыш җыеп алынганнан соң, карт куакларны төбеннән кисеп алырга киңәш ителә. Киселгән ботакларны яндыруың хәерле, чөнки аларда булган авыруларның яшьләренә күчүе мөмкин.

● Эре, куе яфраклы җимеш агачларының артык яфракларын җыйсагыз да ярый. Болай эшләгәндә, яфрактан «котылган» җимеш тизрәк өлгерәчәк. Гадәттә, виноградларны шулай эшлиләр. Яктылык тиешенчә төшкәндә алар тизрәк өлгерә һәм баллы да була.

Помидорны онытма

Хәзер помидорларны фитофторага каршы препаратлар яки сарымсак төнәтмәсе белән эшкәртергә кирәк.

Төнәтмә болай эшләнә. 1,5 кг сарымсакны блендерда изәргә һәм 3 литр суга салып, 5 көн төнәтергә. Әлеге катнашманы 10 литр суга салырга, аңа 50 г хуҗалык сабыны (72 процентлы) кушып болгатырга һәм помидорларның яфракларына сиптерергә кирәк.

Помидорның шулай ук яңа барлыкка килгән чәчәкләрен һәм аскы ботәрләнә башлаган, хәлсезләнгән яфракларын да җыеп алырга кирәк. Бөтен аскы яфракларны берьюлы алырга киңәш ителми. Берничә көн дәвамында 2–3 яфрагын алып тору помидорга стресс тудырмый.

Кыраулар, кичке салкыннар башланганчы помидорларның бер өлешен җыеп куйсаң да ярый. Җыяр алдыннан аларга су сипмәскә киңәш ителә. Өлгергән помидорларны, матур, тагын да тәмлеләнә дип, ботагында озак тотарга тырышмагыз, чөнки ул вак яшел помидорларга үсәргә комачаулый. Өлгергәннәрен җыеп алганнан соң, калганнары да озак көттерми өлгерәчәк.

Тоз балландыра

Кишер белән чөгендерне алырга бер ай чамасы вакыт бар. Алар баллы булсын һәм авыруларга бирешмәсен өчен, тозлы су сибәргә киңәш ителә. 1 стакан җылы суга, өеп, бер аш кашыгы тозны салып эретәсе һәм 10 л суга бутап, алдан су сибелгән түтәлләргә бөркеп чыгасы.

Тәмле булсын!

КЕТЧУП

Миләүшә Сабирова рецепты

Кирәк: 1 кг суган, 4 кг помидор, 4–5 данә татлы борыч, 1–2 ачы борыч, 0,5 кг алма, 1 сарымсак, 4–5 дәфнә яфрагы, 2 аш кашыгы тоз, 10 канәфер, 200–350 грамм шикәр комы, 1 стакан аш серкәсе, 6 түгәрәк кара борыч, 6 хуш исле борыч, 1 бал калагы дарчин (корица).

Яшелчәләрне уртача зурлыкта турарга һәм 2 сәгать уртача утта пешерергә кирәк.

Аннары иләк аша үткәрергә, әлеге массаны кайнатып чыгарырга һәм, стерильләштерелгән банкаларга тутырып, тимер капкач белән ябарга.

«АППЕТИТКА» СОУСЫ

Лилия Мортазина рецепты

Кирәк: 3 кг помидор, 3 баш сарымсак, 1 стакан шикәр комы, ярты стакан үсемлек мае, 0,25 стакан 9 процентлы аш серкәсе, 1 аш кашыгы тоз.

Помидорны иттарткыч аша чыгарып, 1 сәгать кайнаттым. Тоз, май, шикәр комы, сарымсак өстәдем. Тагын 20 минут кайнаттым һәм уксус салып 2 минут кайнатып, каплап тордым. Суынгач, суыткычка куйдым. Бик тәмле була!

Бакчачыга

Җиләге – чиләк-чиләк

Блогер Рафилә Шәмсетдинова бакча җиләге үстерү буенча киңәшләр бирде.

«Мин бакчачы түгел, шулай да хәзерге көндә 10 түтәл җиләгем бар, 150–160 төп тирәсе, быел җиләк мул булды, шөкер», – ди ул.

Үсентеләрне яздан утыртсаң да, көздән утыртсаң да була, дигән нәтиҗәгә килдем!

Бездә җир ашланмаган, түтәл ясап утырттым да куйдым, утыртканда, төбенә мул итеп ком салдым, бакча җиләге ком ярата, диделәр.

Кышка шул килеш калдырам, өсләренә берни капламыйм, алар күп кар сала торган урында безнең! Яз кергәч, төпләрен йомшартам, иске яфракларыннан арындырам.

Бөреләнгәнче мочевина (карбамид) сибәм. 10 литр суга 1 шырпы кабы тирәсе салып болгатып, һәр төпкә 1әр стакан салып чыгам. Чәчәккә бөреләнгәч, өсләренә нашатырь спирты салынган су сибәм (10 литр суга чама белән 2–3 аш кашыгы).

Айга бер тапкыр «Гумат калия» белән ашлыйм, мыекларын кисеп торам, төбенә мулчә җәям (анысы чапкан газоннан).

Сортлары – «Elsanta», «Хоней». Җиләге мул һәм бик баллы. Ремонтант түгел.

Укучы киңәше

КАЙРЫ ЭШНЕ ҖИҢЕЛӘЙТӘ

Быел бакчамны нарат кайрысы белән мулчәләдем. Аның файдасы икән! Бердән, аны түшәгән урыннарда, агач төпләрендә чүп үләннәр чыкмый. Икенчедән, дым саклана, быелгы төсле коры елны бу бик файдага. Өченчедән, үсемлекләрнең тамырын эсседә пешүдән һәм салкында туңудан саклый. Дүртенчедән, матур! Килгән һәрбер кеше әлеге кайрыларга игътибар итми калмады. Хәзер мәнә шуны кура төпләренә дә җәяргә дип торам. Алайса, кычыткан басып интегәм.

Зөлфирә АРСЛАНОВА. Казан

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА әзерләде

ЕЛАГАН КҮЗЛӘРНЕ АЛЛАҺ ЯРАТА

Изге Коръәндә: «Аллаһы Тәгалә кешене көлә һәм елый торган итте», – дип әйтелгән. Чынлап та, кайгы килсә дә, шатлыктан сөенсә дә, кешенең күзләренә яшь йөгерә. Ислам дине елауга нинди караштa? Мәет озатканда, намаз укыганда, өшкергәндә елау – көчсезлекме, әллә ихласлык билгесеме?

Әлеге һәм башка сорауларга Мөдәррис хәзрәт ГЫЙМРАНОВ җавап бирде.

:: Күз яшен күрсәтү – көчсезлек, ди кайберәүләр. Коръәндә елау, күз яше түгү кебек күренешләргә урын бирелгәнме?

– Күз яшен күрсәтүне көчсезлек дип санамыйбыз. Пәйгамбәребез (с.г.в.) дә елаган, моңа мисаллар бар. Елау бары тик кешегә күрсәтү, икейөзләнү максатыннан гына булмасын.

:: Ислам дине елауга нинди карашта?

– Гомумән, елау күренешенә карата ислам дине яхшы карашта. Хәдисләрнең берсендә: «Елаган күзләрне Аллаh яратадыр», – диелгән. Әгәр дә кеше Аллаh каршында икеүдән-икеү генә калып, үзенең гөнаһларыннан гафу сорап, кемнедер югалтуыннан, сагынуыннан, яратуыннан елый икән, моның бернинди дә зыяны юк. Әмма тәкъдирдән зарланып, ризасызлык белән еласа, моны дин хупламый. Тәкъдирнең яхшысы да, яманы да – Аллаһы Тәгаләдән.

Пәйгамбәребезнең (с.г.в.), Ибраһим исемле улы вафат булгач, күзләреннән яшьләр тамган. Мөхәммәд пәйгамбәр: «Дөреслектә, күз елый, йөрәк кайгыра, ләкин безнең йөрәкләр Аллаһыга буйсынган», – ди.

:: Кайбер кеше, мәет озатканда, үксеп еларга мөмкин. Шул вакытта: «Мәет су эчендә ятар, елама», – дип тыючылар да табыла...

– Үксеп елау – хәзерге тормышта гадәти хәл. Әмма Расүлебез дә, динебез дә мәетне озату, аны иская алу буенча төгәл кагыйдәләр билгеләгән. Әйтик, бәргәләнеп, тәгәри-тәгәри, кимнәрне ерта-ерта елаулар тыелган. «Бу мәеткә авырлык китерә», – диелә. «Бәкара» сүрәсендә: «Мин сезне сынармын. Сабыр булганнарны сөендерермен», – дигән сүзләр бар. Гомумән, сабырлык күрсәткәннәргә диндә зур урын бирелә. Сабырлык – татлы җимеш, аның әҗере җәннәт була.

:: Намаз, дога, Коръән укыганда елап җибәрүчеләр, азан тавышын ишетеп елаучылар да бар.

– Кеше Коръән укыганда берничә сәбәп белән елый ала. Шуның берсе – адәм баласының күңеле нечкәрү. «Әгәр дә Коръәнне тауга индерсәк, тау ишелер иде», – дигән Аллаһы Тәгалә. Галимнәр әйтүенчә, адәм баласының

islam.ru

каткан күңелен Коръән җебетә ала. Ул ташны да ярырга сәләтле! Шулай итеп, кеше ихласлыгы артып китеп еларга мөмкин.

Икенче сәбәп – адәм баласында сихер, бозым, күз тию булу. Әйтик, берәр ничек авырып китсәк, организмда аның билгеләре чыга, бу авыруларның дәвалау ысуллары да билгеле. Физиологик авыруларның күрсәткечләре булган кебек, рухи авыруларның да бар. Күз тию, сихернең бер билгесе – Коръән укыганда, намаз вакытында, азан тавышы ишеткәндә елау.

:: Кеше рәнҗегәндә дә елый. Кайберәүләр: «Моңа фәләннең күз яшьләре, рәнҗеше төште», – ди...

– Бер танышымның: «Рәнҗегән кешенең күз яше җиргә түгел, кеше башына тама», – дигән сүзләре бар иде. Рәсүлебез (с.г.в.) үзенең хәдисендә дә: «Әти-әнинең балага кылган, мосафир кешенең һәм рәнҗегән кешенең догасында киртә юк», – ди. Син рәнҗеткән кеше, бәлки, син тыныч кына йоклап яткан вакытта уяудыр, аның күзләрендә яшьләр. Рәнҗү, каргау – хәтәр нәрсәләр. Гафу итә һәм гафу сорый белик.

Гыйбрәтле кыйсса

Иң зур җиһад

Бервакыт бер көрәштән кайткач, сәхабәләре бик нык сөенгәндә, Расүлебез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән:

– Без кечкенә көрәшне җиңдек, әмма алдыбызда иң зур яу бар.

Сәхабәләре, бу сүзләргә гаҗәпләнеп, Аллаһының Расүленнән: «Нинди яу



pinterest.com

соң ул? Моннан да көчлерәк яу була аламыни?» – дип сораганнар.

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип җавап биргән:

– Әйе, әле алдыбызда иң зур яу бар. Ул да булса – нәфесебез белән көрәшү.

Әмма борчыган мәсьәлә дә бар. Бу – физика, химия, биология, математикадан (профиль) имтихан тапшыручылар саны кимү. Илсур Һадиуллин проблеманы уку йортларында инженер белгечлекләренә кабул итү кагыйдәләренә, югары квалификацияле фән укытучылары җитмәүгә бәйләп аңлатты. Моны хәл итү өчен махсус программа кирәк булачак.

БДИда имтиханнар сайлау күрсәткече*

Фән	2022	2023
Математика (профиль)	50,8	50,5
Физика	17,0	14,1
Химия	12,8	12,3
Информатика	16,7	20,8
Биология	17,2	16,6

* процентларда

Акыллы башларның читкә китүе

Республикада быел 199 укучы БДИда 100 балл җыйса, тугызының хезмәте – 200 баллык. Якынча мәгълүматлар буенча әлеге ике йөз балл җыйган тугыз егет һәм кызның җидесе Мәскәү, Санкт-Петербург вузларын сайлаган. Узган ел исә ике йөз балл туплаучы егет-кызлар 14 иде. Шуларның алтысы Татарстаннан читтә укуын дәвам итә. Министр республика вузлары ректорлары, предприятие җитәкчеләренә мөрәҗәгать итеп, акыллы башларны үзебездә калдыру юлларын эзләргә, үзебездә дә алга таба үсеп булуын аңлатырга кушты. КФУның йөз балл туплаучыларга 300 мең сумга кадәр стипендия түләвен уңай бәяләде.

Ялтырамаган медальләр

Быел чыгарылыш укучыларының 1931е алтын медаль алган. Узган ел бу сан 2 меңнән артык иде. Кызганыч, 208 укучы медален аклый алмаган. Билгеле булганча, медальгә дәгъва кылучылар математика һәм рус теленнән БДИда 70тән ким балл җыймаска тиеш. Юкса медаль эләкмәячәк. Быел математикадан – 140, рус теленнән 32 укучының баллары әлеге күрсәткечтән түбән булган. 33 укучының исә ике фәннән дә нәтиҗәләре мактанырлык түгел. Алексеевск, Кайбыч, Лаеш, Апас, Чүпрәле һәм башка районнарда укучыларның өчтән бере әлеге имтиханнарда 70 балл җыя алмаган.

Ачылмаган сыйныфлар

Министр кайбер районнарда 10 нчы сыйныфка укучылар тупланмау, профиль сыйныфлары оештырылмауны да тәнкыйть утына тотты.

Республикада ел саен 9 нчы сыйныф укучыларының яртысы көллиятләргә укырга керә. Яңа уку елында барлыгы меңнән артык унынчы сыйныф ачылачак. Тик 57 мәктәптә бу эш бөтенләй оештырылмаган. Проблема бигрәк тә Менделеевск районына хас. Әйтик, анда 15 урта мәктәп исәпләнсә, шуның алтысында гына унынчыга кабул итәчәкләр.

Рәхмәт ишетү рәхәт

Илсур Һадиуллин тиздән яңа уку елы башлануын искә төшереп, барлык мәгариф оешмалары, район һәм мәгариф идарәсе башлыкларына белем йортларын иминлек белән тәэмин итәргә кушты. «Бу мәсьәләдә ваклыклар юк!» – диде, катгый итеп.

Республика Рәисе Рөстәм Миңнеханов киңәшмәдә бер генә тәнкыйть сүзе дә әйтмәде. Бары алга таба укытучыларның һөнәри әзерлегенә генә игътибар итәргә өндәде. Узган уку елында мәгариф өлкәсендә зур эш башкаруы укытучыларга, мәгариф оешмалары җитәкчеләре, район башлыкларына рәхмәтен җиткерде.

– Укытучының абруе бик мөһим. Югары уку йортларында белем бирүче мөгаллимнәр турында да оныткырга ярамый. Бу сорауларны хәл иткәндә ректорларны чакырыгыз, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Киңәшмә ахырында Рәис республиканың иң яхшы укытучыларына дәүләт бүләкләре тапшырды. Казанның 18 нче гимназиясе укытучысы Рәмзия Шәрәпова һәм Казан төзелеш, архитектура, шәһәр хуҗалыгы көллияте мөгаллимәсе Тамара Вәлишинага «Татарстан Республикасының халык укытучысы» исеме бирелде.

Сүз уңаеннан, Укытучылар һәм остазлар елында Казансу елгасы яр буенда быел укытучыга һәйкәл төземәкчеләр. КФУ янәшәсендә «Белем» музее ачарга җыеналар.

Сәрия МИФТАХОВА

Сан

Узган уку елында республикада 1984 балалар бакчасы, 1410 мәктәп эшләгән. 487 меңгә якын укучы белем алган, 210 меңнән артык сабый бакчага йөргән.



БӘЯЛӘНМИ КАЛГАН БАТЫРЛЫК

Мари Эл Республикасында Бөек Ватан сугышында ятып калган милләттәшләребезне барлыйлар, хәбәрсез югалганнарны ачыклыйлар, тапшырылмаган бүләкләрне туганнарына кайтарырга ярдәм итәләр.

Боларның барысы белән дә Сания ГАЗИЗҖАНОВА җитәкчелегендәге Мари Эл Республикасы «Татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте» региональ иҗтимагый оешмасы шөгыльләнә. Сания ханымның шундый милләтпәрвәр булуына гаҗәпләнәсе дә юк. Ул – «Идел-Урал» легионында яшерен төркемне оештырган һәм җитәкләгән Гайнан Кормашның туганы. Төбәкчеләрнең эш-гамәлләре турында әңгәмә корганда, аңлашыла ки, сүзебез күбрәк шул тирәдә барды.

:: Сания ханым, сезне еш кына Бөтендөнья Татар конгрессында үткәрелгән чараларда очратам. Гел чыгышлар да ясап торасыз. Шуңа күрәдер инде, без Мари Эл Республикасындагы хәлләрдән шактый хәбәрдар. Башка төбәкләр өчен дә яхшы үрнәк бу. Татарстан белән тыгыз элемтәдә булу эшегезне шактый үтемлерәк итәдер, мөгаен?

– Әлбәттә. Әле бүген дә «хәбәрсез югалган» милләттәшләребез бик күп бит. Шуларның язмышын ачыклыйсы, балаларына, оныкларына ярдәм итәсе килә. Күңелдә шундый уйлар тугач, ярдәм сорап, Татарстанга мөрәҗәгать иткән идек. Михаил Черепанов җитәкчелегендәге «Хәрби дан клубы» ассоциациясе белән берлектә «Россиядә сугыш җиле кагылмаган бер гаилә дә юк...» («Нет в России семьи такой») проектын тормышка ашырдык. Хәзер исә «Игелекле исемен кайтарырга» («Вернуть доброе имя») проекты өстендә эшлибез. Нәтиҗәләр дә сөендерерлек: Бөек Ватан сугышыннан кайта алмаган дүрт меңнән артык милләттәшебезнең исемен ачыкладык.

:: Россиянең башка төбәкләре белән дә элемтәдә торасызмы? Бәлки башка җирләрдә дә сездән үрнәк алып, кызыксынып китәрләр иде.

– Документлар белән эшләгәндә, әллә нинди мәгълүматларга тап буласың. Берсен дә игътибарсыз калдырмаска тырышабыз. Башкортстан, Удмуртия, Мордва һәм Чечня республикаларына, Омск, Ульян, Кемерово, Томск, Самара, Пенза һәм Түбән Новгород өлкәләренә, Пермь краена исемлекләр туплап җибәрдек инде. Ниләр эшләргә мөмкинлеген аңлаттык.

:: Конгресста Хәтер һәм кайгы көне уңаеннан үткәрелгән конференциядә Гайнан Кормашны аерым телгә алган идегез...

– Сәбәпләре дә саллы бит. Беренчедән, ул – безнең якташыбыз. Икенчедән, ерак туганым. Гайнан Кормаштан соң мин – өченче буын вәкиле. Аның язмышын ачыкларга абыем Васил тотынган иде. Ул безнең Кормаш нәселенең шәҗәрәсен әтисе Гайсә сүзләреннән һәм язмаларыннан чыгып төзегән. Әлбәттә инде, Гайнан абыйның батырлыгы дошман тылында барган вакыйгаларга бәйле. Шуңа күрә легион тарихына да тукталып китәргә кирәк дип уйлыйм.

1942 елда Гитлер командованиесе зур югалтуларга дучар ителә. Алгы сафта ут эченә кертер өчен аларга «армия» кирәк була. Шушы максаттан, «Идел-Урал» дәүләте төзибез дигән ялган белән, татар һәм башкортлардан легион оештыра башлыйлар. 1941–1942 елларда лагерьларда йөз меңнәрчә әсирләр ачлыктан, төрле авырулардан егыла. Һәм... аларны кинәт кенә яхшы ашата, киендерә башлыйлар, хәтта дини чаралар үткәрергә рөхсәт итәләр, татар телендә язылган листовкалар тараталар. Оренбург татары Шәфи Алмаска милләттәшләре арасында агитация эшләре алып бару йөкләнә. Германия пропагандистлары татарларны төркиләр арасында «беренче халык» дип атыйлар. Шулай итеп, әсирлеккә төшкән 25 мең татар дошман формасы кия. Әлбәттә инде, күбесе моны исән калу ниятеннән эшли.

Шул ук вакытта Кызыл Армия Генераль штабының Баш разведка идарәсе легионда яшерен төркем төзү турында карар кабул итә. Моның өчен легионга махсус разведчиклар, офицерлар, политруклар кертелә. Алар арасында Гайнан Кормаш та була. Аңа яшерен оешманы җитәкләргә тәкъдим итәләр. Бу оешмага кергәндә аңа герой-шагыйрь Муса Җәлил үзе дә ант бирә. Яшерен төркем ун меңнәрчә милләттәшләрен фашистлар белән хезмәттәшлек итмәскә өндәргә тиеш була. Алар татарларның хыянәте СССР территориясендә яшәүче бар халыкны зур фаҗигагә китерәчәген аңлаталар. 25 мең легионерны хыянәт итүдән саклап калырга концерт программасы да ярдәм итә. Бу эштә Гайнан Кормаш башлап йөри. Ул хәтта «Шүрәле» дип аталган пьеса яза. «Бер төркем артист» төрле лагерьларда спектакль куя. Бу исә әсирләр белән аралашырга ярдәм итә. Кормаш җитәкләгән төркем хәтта СССР Совинформбюро хәбәрләре язылган листовкаларны таратырга да мөмкинлек таба. Анда фронттагы хәлләр турында язылган була.

1943 елның 23 февралендә татар милләтеннән булган бер меңгә якын әсир Белоруссиянең Витебск районындагы партизаннар бригадасына күчәргә җыена. 800 кеше корал, шул исәптән пушкалар, минометларны үзе белән алып, теләгенә ирешә. Калганнары өлгерә алмый, чөнки бу хәлгә нокта кую өчен, фашистлар фронттан танк частьлары китертә. Гитлер, бу хәлләрне ишетеп, чыгырыннан чыга һәм «Идел-Урал» легионын фронттан ераккарак күчерергә куша.

Җәзалап үтерелгәндә Гайнан Кормашка бары тик 25 яшь була.

> Германиядә татарлар белән арадашчы ролен үтәгән Стамати: «Татарлар Совет Армиясенә каршы сугышмаячак, чөнки алар туганнарының язмышы өчен борчыла. Алар өчен иң әһәмиятлесе – милләтне саклау, ватанпәрвәрлек. Татарлар бик акыллы, аларны дини фанатизм белән генә көчсезләндереп булмый».

1943 елның августында Кормаш һәм аның иптәшләре Польша территориясендә кораллы восстание күтәрергә әзерләнә. Әмма немец разведкасы да йоклап ятмый. Каты җәзалаулардан соң Казахстаннан Ямалетдинов фамилияле яшерен оешма әгъзасы «сына»: үзе белгән кешеләрнең исемнәрен санап чыга. Шулай итеп, Гайнан Кормаш иптәшләре белән кулга алына. Араларында Муса Җәлил дә була.

Әмир Үтәшев җитәкчелегендәге төркемнең иректә калган әгъзалары Франция, Бельгия һәм Нидерланд партизаннары белән уртак тел табалар. 1944 елның 15 августында алар союздаш гаскәрләргә Франциянең көньягына төшәргә һәм 24 августта Парижны азат итәргә ярдәм итәләр. Нәкъ менә шушы хәлләрдән соң яшерен оешманың җитәкчеләре Берлинда гильотинада җәзалап үтерелә дә инде. Алар бөтен Советлар Союзындагы татар халкының намусын саклап калалар һәм Идел буе халкын депортациядән коткаралар. Без мондый хәлләрне калмыклар, Кырым татарлары, чеченнар һәм балкарлар мисалында беләбез.

:: Яшерен оешмада Гайнан Кормаш төп рольне уйнаган булса да, читтәрәк калды кебек?

– Әйе, барлык баш разведчиклар әле дә сер булып кала. Без күп еллар эзләнү эшләре алып барабыз. Оборона министрлыгының Үзәк архивында шәхсән үзебез булдык. Анда лейтенант Кормашев турында беренче документ та юк.

Шул ук вакытта тарих фәннәре докторы, армия генералы, хәрби фәннәр академиясе президенты Мәхмүт Гәрәев үзенең мәкаләләрендә һәм «Татарлар фашизмга каршылык күрсәтәләр» повестенда бу хәлләрне таныун яза. «Каршылык төркемен оештыручы булып Кызыл Армиянең иң яшь офицеры, командованиенең махсус йөкләмәсе белән әсирлеккә эләккән Гайнан Кормашев тора. Алар легионерларны партизаннар ягына күчүгә һәм лагерьдан качуга гына түгел, ә фетнәгә әзерлиләр», – ди ул.

Димәк, ачылмаган серләр күп әле. Документлар яшерен булу аркасында гына гитлерчылар тарафыннан җәзалап үтерелгән күпме кешегә, шул исәптән татар халкы өчен гаять зур яхшылык эшләгән Гайнан Кормашка тагылган «гаепләр» бүгенгәчә акланмый. Шуңа күрә хәтта кече ватаннарында да без аларга тиешле хөрмәтне күрсәтә алмыйбыз. Батырлык һаман да бәяләнми.

Әңгәмәдәш –
Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

✯ Мари Эл Республикасы Бәрәңге районының Гайнан Нури улы Кормашев туып-үскән Куян авылындагы мәктәп диварына 2005 елның 15 февралендә мемориаль такта куелган. Ул сугышка кадәр бу мәктәптә укытучы булып эшләгән.

✯ Бәрәңге һәм Куян авылларында урамнар Гайнан Кормаш исемен йөртә.

✯ Куян урта мәктәбендә ел саен «Кормаш укулары» үткәрелә.

БЕР КӨНДӘ ӨЧ БАЛАСЫН ЮГАЛТКАН ГӨЛСИНӘ КАМАЛОВА:

«КЫЗЛАРЫМ ҖЫЛЫСЫ КУЕНЫМДА»

Язылганга кире кайтып

Бу язманы укый башлагач, күпләр 2014 елның 8 августын исенә төшерер, мөгаен. Бу көнне Питрәч районының Ильинка авылы янәшәсендәге юл фаҗигасендә өч бертуган кыз һәм аларның дуслары һәлак булды. Бу хәбәрне ишетеп, бөтен Татарстан елады. Өч баласын бер көндә җиргә иңдергән ана язмышы бик кызганыч иде. Кызлар үзләре... Алар әле яши генә башлаган иде бит! Сабырлыкның никадәр авырлык белән бирелгәнен өч бертуган кызның әнисе Гөлсинә апа үзе генә белә торгандыр...

– Кызларым Алсинә, Алинә, Гөлинәмнең алма кебек матур чаклары иде. Кияүләргә биреп, тормышларына сөенеп, сабыйларын сөеп кенә яшәр идем дә бит. Тик язмышлары бөтенләй башка булган икән сабыйларымның. Өч бала үстереп буйга җиткердем дә, берсе дә калмады, – ди ул.

Күңеленә авыр булса да, Гөлсинә апа белән 9 ел элек булган хәлләрне искә төшердек. Алсинә Базарлы Матакта банкта эшли, 19 яшьлек Алинә – кооперация институтында, 18 яшьлек Гөлинә технология колледжында дизайнерлыкка укый. Иртәгә фаҗига буласы дигән көнне олы кызы Алсинәгә 27 яшь тула.

– Туган көнгә бардым. Кызыма багышлап, матур җыр да башкардым. Ул да миңа шундый матур сүзләр әйтте.

Гаилә архивыннан

Синдәй әнием булмаса, мин мондый табыннар кора алмас, яхшы машинада йөрмәс идем, диде. Өстәл аша үрелеп кочаклады. Шул җылысы әле дә куенымда тора кебек. Дуслары да, кызымны мактап, матур сүзләр әйттеләр. Бик күңелем булган иде, – дип искә ала Гөлсинә апа. – Алсинә – беренче никахтан туган балам минем. Әтисе кыска гомерле булды. Ирем үлгәч, Рөстәм абыегызга кияүгә чыктым. Уртак кызларыбыз Алинә белән Гөлинәбез туды. Кайбер атнада кызларым, киткәндә, үзләре артыннан җыеп та өлгермиләр иде. Бу юлы бөтен җир тәртиптә калган. Мунчаны да җыештырып, юып киткәннәр. Әйтерсең күңелләре сизенгән. Эшләрен калдырмаганнар.

Фаҗигане ана күңеле сизенә. Кичке алтыда киткән кызлар сигездә дә хәбәр бирми. Гөлсинә апа башта бер кызына, аннан икенчесенә, соңыннан рульдә барган Алсинәгә шалтырата. Берсе дә телефонын алмый. Өзгәләнә ана йөрәге. Җанына урын тапмый. Шул вакытта кызлар үлгән була инде. Башка машинаны узам дип каршысына килеп кергән автомобильгә бәрелмәс өчен, Алсинә тормозга баса һәм ручникны күтәрә. Алар утырган машина шундук асфальтка килеп кадалган һәм йөк машинасына килеп бәрелгән. Дүрт кыз дүрт якка очкан.

Әниләре сөйләвенчә, апалары сеңелләренә гел терәк була. Кечкенәдән. Алар авырса да ярдәм итә. Укырга кергәндә дә таяныч була. Бик дус яшиләр. Бер-берләреннән башка тора да алмыйлар. Якты дөньядан да бергә, өчәүләшеп китеп бара алар. Вакыт дәвалый, дисәләр дә, Гөлсинә апа килешми. Ана балаларын ничек оныта алсын инде?! Ул аларны сагынып яши. Догалар кыла. 2015 елда дингә килүе яшәргә ярдәм итә дә инде аңа.

– Кызларымны югалткач, әле тагын сынаулар килде. Энемнең хатыны яман чирдән үлеп китте. Гаиләбез өчен бик авыр югалту булды. Ике ел элек иремне дә югалттым. Бала хәсрәтләре эзсез югалмады инде. Рөстәмем йөрәк белән 61 яшендә арабыздан китеп барды, – ди Гөлсинә апа. – Аннан соң Казанда яшәүче апамда яман шеш таптылар. Балалары белән сөйләштем дә аны үзебезгә кайтаруларын сорадым. Апамны тәрбияли алдым, шөкер. Тик чирне җиңә алмадык. Ул да китте.

Гөлсинә апаны туганнары ташламый. Бер дә ялгыз торганым юк, ди ул. Ялгызлыгын сиздермәс өчен,ниләр генә эшләми икән якыннары. Үзе, кирәкми, дисә дә, күптән түгел 65 яшьлек юбилеен уздырганнар.

– Янәшәмдә терәк булырдай кешеләрем бар. Үзем дә сабыр итәргә тырыштым. 8 ел мәдрәсәдә белем алдым. Гарәпчә укырга өйрәндем, – ди Гөлсинә апа. – Язмыш никадәр генә сынаса да, түзәргә кирәк. Елап кына берни үзгәртеп булмый. Кызларым да кире кайтмыйлар. Бер генә теләк – догаларым һәркайсына барып ирешсә иде. Сагынам. Бик сагынам үзләрен. Өч кызымның фотосын да ясатып элеп куйдык. Карап кына торам үзләренә. Әле ярый төшләремә кергәлиләр. Буй җиткән вакытлары түгел, кечкенә чаклары керә. Шул төшләремне күреп тә сөенеп уянам мин. Уыннары оҗмахта булсын инде кызларымның. Бар теләгем шул. Үзләре дә риза-бәхилдер.

ЯТИМНӘРГӘ НАЗ КИРӘК!

Үзе тигезлектә үскән кеше ятим хәлен аңламаска да мөмкин. Ә «әти», «әни» сүзләрен әйтергә интеккән кешегә һәр ятим якын. Ул кешедә үксезләр өчен җылы табыла. Чирмешән районының Утыз Имән авылында яшәүче Разия Мәхмүтованың да йөрәге тулы ярату. 86 яше белән бара торган әбекәй оныклары өчен утка-суга керергә әзер.

– Әтием ятим үскән минем. Кечкенәдән өебездән кеше өзелмәде. Апам пешерергә оста иде. Кергән кешене сыйлап чыгардык. Әтинең юмартлыгы, кешелеклелеге безгә дә күчкән, – дип искә ала Разия әби. – Без 6 бала идек. Инде бүтәннәр берсе дә исән түгел. Миңа Аллаһы Тәгалә гомерне кызганмаган. Яхшылыкларым өчен дип биргәндер инде.

Разия апа ире Азат белән 50 ел гомер кичерә. Ул аңа дүртенче хатын булып кияүгә чыга. Азат абыйның беренче хатыны ике баласын ятим итеп үлеп киткән була. Аннан соң тагын ике тапкыр өйләнә әле. Әмма яшәп китә алмыйлар. Разия апа аңа ятим балаларны кызганып чыга. Иренең ике баласын да үстерә, уртак 4 балалары була. Гомере буе колхозда эшли. Сыерын да сава, басуына да өлгерә. Ире агач эше остасы була. Тормышта төрле чаклар булса да, зарланмый әбекәй. Бала хәсрәтләрен дә сабырлык белән җиңә.

– Ирем белән яхшы тордык. Күзләр белән генә сөйләшә идек без. Сабырлыгым булышты. Язмыш сынады инде ул, бәбкәм. Бер баламны табибләр ярып алдылар. Ул озак яшәмәде, икенче көнгә үлде. Икенче улымны ток сукты. Фәрит белән Хәмитнең яшь аралары бер ел да юк иде. Алар гел бергә булдылар. Мунчага бергә керәләр иде. Юынып кайтканда, токка эләктеләр. Фәритемне коткарып калдык, Хәмитем үлде. Ике балам исән-сау. Халидә бик сирәк кайта. Хәлитем ташламый инде. Ни генә булса да, янымда ул, – ди Разия әби.

Аны авылдашлары да хөрмәт итә. Барысы да мактап телгә ала. Сеңлесе Әлфиянең тәрбиягә алган кызы Алсуны да үстерә әле ул. Алсу башта ятимнәр йортында яши. Инде гаиләле булдым дигәч кенә, әтисе үлеп китә, аннан соң 15 яшендә әнисез дә кала. Чит күрмиләр аны. Алсуны башта апасы Халидә тәрбияли, 11 нче сыйныфта Разия әбисенә кайта.

– Әнинең апасы булса да, без аңа әби дип эндәштек. Әниемнең әти-әнисе яшьли үлгән иде. Шуңа да зур апасы әби булды. Ул мине бик яратып үстерде. Үзем дә әбием белән бабаем янында тынычлык таптым. Әби мине дөрес тәрбияләде. Үзе колхозда эшләгәч, мине укытасы килде. Гел: «Кеше бул!» – дип торды. Шөкер, әби теләгәнчә булды барысы да. Укыдым да, шәһәрдә дә яшим, гаиләм дә бар, – ди Алсу.

Әбисен бик ярата ул. Кечкенә балалары булгач, янына еш кайта алмаса да, күңеле белән әбисе янында инде. Хәер, әле менә Разия апа да, мин 86да, дип тормаган, Алсу икенче кызын тапкач, бәби күрергә дип, Чирмешәннән Казанга килгән. Кулында бары тик кызының телефон номеры гына була. Ничек итсә итә, кешеләрдән ярдәм сорап, кызына Казанда икәнен хәбәр итә. «Бик күрәсем килде», – ди Разия апа.

Алсуы кебек кадерләп үстергән тагын бер баласы бар аның. Кызының кызы Гөлинәне дә үз канаты астына сыендыра ул. Гөлинә, 6 нчы сыйныфта укыганда, әби белән бабай янына күченеп кайта.

– Күңелеңдә яхшылык бар икән, кешеләрне яратып була. Гомерем буе янымa ятимнәр җыелды. Иремнең ике баласы да исән түгел инде. Аларның балалары әле дә хәлемне сорап тора. Бар теләгем – ике кызымның бәхетле булуын күрү. Алсуым өчен сөенәм. Намазга басты, ире дә акыллы, кода-кодагыйлар да үзләренең балалары кебек кабул иттеләр. Минем күңел тыныч. Әле менә янымa кайтып тордылар. Алсуым бөтен җиремне ялт иттерде. Шул арада әнисенең чардуганнарын да буяп кайтты. Бик мәгънәле бала. Кешеләргә ачу сакламый. Ташлап калдырган әнисен дә эзләп тапты. Аңа ачу саклаудан ни файда? Кем хаталанмый инде... – ди Разия апа.

Алсу үзе әбисенә бик рәхмәтле. Иң авыр чакларда терәк булды, ди.

– Безнең әби беркайчан да тегеләйболай эшлә дип өйрәтмәде. Әйткән сүзеңне тыңлар иде. Хуплады да. Үсендерә белде. Ул булганда, мин әле дә сабый. Исән генә булсын, телефоннан тавышын ишетсәм дә, мин бәхетле, – ди Алсу.

Гаилә архивыннан

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

НӘСИМ АКМАЛ:

«БЕЗНЕҢ ӘДӘБИЯТ ДӨНЬЯ КҮЛӘМЕНДӘ ТАНЫЛУГА МОХТАҖ»

Бөекләрен күтәрә белгән халык бөек була. Журналист, «Татарстан» радиосындагы күп тапшырулар авторы Нәсим АКМАЛ белән әңгәмәбез нигезендә әнә шул фикер ята. Без ул бөеклекне яулый алдыкмы? Дагыстан халкыннан нәрсәгә өйрәнергә кирәк? Бүген без кемне күтәрергә тиеш?

Рәсүл Гамзатов истәлегенә багышлап, журналист Нәсим Акмал әзерләгән тапшырулар циклы өчен «Татарстан» радиосы Дагыстанда үткән «Голос Евразии» фестивалендә гран-прига лаек булды. Әлеге тапшырулар Рәсүл Гамзатовның «Минем Дагыстаным» әсәренә нигезләнгән.

– Безнең бу әсәргә элек тә мөрәҗәгать иткәнебез бар иде. Аның туган илгә, Ватанга, халык язмышына кагылышлы уйлануларын эфирга биреп бардык. Хәзер инде китап тулысынча тәрҗемә ителде. Радиода тапшырулар циклы да дәвам итәчәк.

:: Рәсүл Гамзатов иҗаты безгә ни өчен якын?

– Аның әсәрләре – синең турында да, минем турында да, Россиядә, юк, хәтта планетада яшәүче бөтен халыклар турында да. Һәркем анда үзенекен таба. Мәхәббәт хакында язсынмы, үз замандашларын борчыган мәсьәләләр хакындамы, туган телме, туган илме – безнең күңел тибрәнешләренә туры килә.

:: Күптән түгел Дагыстанда булып кайттыгыз. Ишеткән-күргәннәрегез турында сөйләгез әле.

– Безне Рәсүл Гамзатовның туган ягы – Хунзах районының Цада авылына алып бардылар. Таулар арасындагы шул авылга килеп төшкәч, андагы һәрнәрсә таныш тоелды. Аның әсәрен тәрҗемә иткән чакта туган сорауларыма да җавап таптым.

Ренат Харисның шундый сүзләре бар: «Бөекләрен күтәрә белгән халык бөек була». Ул сәфәремнән мин шушы сүзләрнең чыннан да дөрес икәнлегенә инанып кайттым. Дагыстан халкы үзен нәкъ менә әдәбият, сәнгать аша – Рәсүл Гамзатов аша күтәргән. Аңа Ленин һәм Сталин премияләрен, «халык шагыйре» исемен биргәннәр, чит илләрдә йөрткәннәр. Ә ул үзе таулар һәм диңгез арасында качып яткан кечкенә генә Дагыстанын нинди югарылыкка күтәргән! Аның аша Дагыстанны бөтен дөнья белә.

> Менә кайда хикмәт. Менә нинди акыллы халык яши анда! Халык – шәхесне, шәхес халыкны күтәргән. Миңа калса, бу турыда безгә дә уйланырга кирәк. Халыкны таныту өчен ниндидер вак-төяк нәрсә генә җитми. Халыкны әдәбияты, сәнгате аша танылар. Шагыйрьләре, рәссамнары, композиторлары аша...

Рәсүл Гамзатовны анда пәйгамбәр урынына күрәләр. Әйтик, бездә Тукайның «Туган тел» шигырен яттан син сөйләсең дә, мин сөйлим. Ә анда бөтен кеше Рәсүл Гамзатов гыйбарәләре белән сөйләшә. Бер генә мисал: безне Камалетдин атлы бер шофер йөртте. Рәсүл Гамзатов әсәрен татар теленә тәрҗемә иткәнемне белгәч, туганы кебек якын күреп сөйләште, кунакка чакырырга тотынды. Шаккаткыч бит!..

:: Үзебезнең әдәбиятка әйләнеп кайтсак, бездә дә шул югарылыкка күтәрердәй шәхесләр бар бит...

– Дагыстан әдәбияты белән электән кызыксынам бит инде. Ягъни чагыштырылык тәҗрибәм бар. Безнең әдәбият – зур әдәбият ул. Бу бәхәссез. Дагыстан әдәбиятын бәләкәй дип әйтмим, безнеке зуррак та димим. Әмма татар әдәбияты зур һәм көчле. Бу элек тә шулай булган, хәзер дә шулай. Бездә, бер генә түгел, бик күп шагыйрьләр-язучыларны шул югарылыкка күтәрергә мөмкин иде. Әйтик, Зәки Нурины гына алыйк. Бөек Ватан сугышында партизаннар берләшмәсенең разведка командиры булып кайткан егет. Өстәвенә яхшы каләмле шагыйрь. Әмма төрле сәбәпләр аркасында, аны читтә генә түгел, хәтта бездә дә белмиләр диярлек.

:: Ә Тукайны?

– Советлар Союзы заманында Муса Җәлилне бик күтәрделәр. Гомумән, җәлилчеләрне. Алар һәркайсы – бөек шәхес. Безгә Муса Җәлил баскан һәр эзне алтын белән әйләндереп алырга кирәк иде. Тукай – әлбәттә, зур шәхес. Аны барлык төрки халыклар таный. Ләкин дөнья күләмендә танылу өчен җәлилчеләр эффектлырак. Безгә нәкъ менә аларны күтәрергә кирәк. Зур иҗатларыннан тыш, аларда кешенең игътибарын җәлеп итә торган батырлык, егетлек кебек сыйфатлар да бар. Теге чорда Муса Җәлил әсәрләрен төрле телләргә тәрҗемә иттеләр. Элеккеге Советлар Союзы дәүләтләрендә яшәүче безнең буын аны әле дә белә. Ә яшьләр – юк. Читтә генә түгел, Россиядә дә белүче сирәктер хәзер. Ә ул – татарның бер символы булып, әдәбият аша дөньяда танылу мөмкинлеге...

Риман Гыйлемхановның Казакъстанда, Уральскида булып кайтканнан соң сөйләгәннәре әле дә истә. Андагы музейларның берсендә ниндидер бер баскычның кечкенә өлеше тора, ди. Нәрсә икән бу, дип кызыксынган. «Бу баскычка Тукай басып узган булырга мөмкин, шуңа ул безгә бик кадерле», – дип җавап биргәннәр. Менә нинди ихтирам! Бездә менә шундый караш юк.

> Югыйсә Тукайны да, Җәлилне дә, башкасын да үзебез кадерләмәсәк, аларны башка халык килеп кадерләмәячәк. Үзебез дөньяга таратмасак, башкаларга аның кирәге юк.

:: Тәрҗемә турында әйтә башладыгыз. Бүген без аның әһәмиятен аңлап җиткермибез кебек. Бик беркатлы сорау булса да, әйтегез әле, безнең әдәбиятны башка телләргә тәрҗемә итәргә кирәкме?

– Бик әһәмиятле сорау бу. Безнең нинди әдәбиятыбыз бар!.. Аның зурлыгын башка халыклар да таный, күпләр аны өлге итеп саный. Хәтта кабатларга тырышып иҗат итүчеләр дә бар. Ягъни ул, һичшиксез, танылырга, башка телләргә тәрҗемә ителергә лаеклы һәм... моңа мохтаҗ да.

:: Шул ук Рәсүл Гамзатов иҗатын балалар рус әдәбияты дәресләрендә дә өйрәнә. Ягъни ул мәктәп программасына кертелгән. Милли әдәбият өчен – шактый зур нәрсә, килешәсездер?

– Гениаль нәрсә бу! Татар әдипләреннән Муса Җәлилне дә кертергә кирәк. Бүгенге вазгыятьтә бу аеруча мөһим. Ул бит – каһарман, герой. Гомумән, рус әдәбияты дәреслекләрендә Россиядә яшәүче барлык халыкларның да вәкилләре булырга тиеш, минемчә. Шул очракта гына ул Россия, рус әдәбияты дип атала ала. Россиядә яшәүче барлык халыкларның мәдәнияте йогынтысында барлыкка килгән әдәбият бит ул! Аннан соң, бала мәктәп яшеннән үк теге яисә бу халык турында әдәбият аша белә дигән сүз бит ул.

:: Татар әдәбиятын, элек тә зур булган, хәзер дә шулай, дидегез. Ә бит бүгенге әдәбиятны, бигрәк тә яшьләр иҗатын тәнкыйтьләүчеләр күбәеп китте. Бу хакта ни уйлыйсыз?

– Әдәбиятта гел шулай булган инде ул. Яшь иҗатчыларны алсак, араларында бик тирән фикерле, гаҗәеп талантлылары да, әле өйрәнеп кенә килүчеләре дә бар. Һәр эштә тәҗрибә кирәк булган кебек, әдәбиятта да тиз генә югарылыкка ирешү кыен. 5, 10, 15 елдан яшьләр нәрсә язар? Белмибез бит. Әйтик, 1970 нче елларда туган буынны, әдәбият чылбырын өзде, дип сөйләделәр. Ахыр чиктә ул буын арасыннан үзе генә дә 10 язучыга торырлык Марат Кәбиров үсеп чыкты. Кулына каләм алган гына чакларында берәү дә аны даһи булыр дип уйламагандыр.

Сәләтле яшьләр бар, әмма аларны укучы булырмы? Менә кайда мәсьәлә. Татарча китаплар, газета-журналлар укучылар, радио тыңлаучылар булырмы?

Әңгәмәдәш – Лилия ГЫЙМАЗОВА

ӘҢГӘМӘ ТУЛЫСЫНЧА VATANTAT.RU САЙТЫНДА

АЙГӨЛ ӘХМӘТГАЛИЕВА

ТУЗГАНАК КЕРФЕГЕ

< Ахыры. Башы 14, 21, 28 июль, 4, 11 август саннарында

Артыгын ычкындырды Мирхәт, Мәрфуганың авырткан сөяленә басты. Ире сугышка киткәннең икенче аенда ук төнлә капка каккан Мирхәтне ачып керткән иде шул хатын. Бәләкәй балаларыннан аерып, урман кисәргә җибәрмәсеннәр дигән курку аның гына түгел, күпләрнең капкасын ачтырды. Шул төннән бирле Мирхәтне янәшәсендә күргән саен Мәрфуганы аннан да, үзеннән дә җирәнү тойгысы биләп ала, хатын күзгә күренеп картаеп китә иде. Ярый әле бу адәм актыгы аның катына түшәк бүлешергә дип башка аяк басмады, мыскыллы елмаеп: «Бүрәнә ни, син ни», – дип чыгып китте дә күзгә-башка күренмәде, шунысына булса да шөкер итәрлек.

Мирхәтнең соңгы сүзләре Мәрфуганың сабыр савытын мөлдерәмә тутырды, ул тиен җитезлеге белән сикереп тә торды, аягындагы чабатасын салып, алдын-артын уйламыйча, шуның белән ирнең йөзенә кизәнде.

– Хәшәрәт! Безнең ирләр ут эчендә йөри, син монда аларның хатыннарын басып рәхәтләнәсең! Кайтсыннар гына, фәлән җиреңне кисеп кулыңа тоттырырлар әле!

– Әйтмә! Бер бетмәсә, бер бетәр әле сугышы да...

Күмәк булганда хатыннар бер йодрыкка әйләнә иде, алар, бер-берсенең сүзен куәтләп, Мирхәтнең өстенә килә башладылар. Чабата әләккән яңагын кысып тоткан ир арткарак чигенде, аннан плащының өске төймәсен ычкындырып, муенын ата каз кебек боргалагандай итте дә, Хәдичәгә карап:

– Боларны син котыртасың, контра, җавабын да син бирерсең! Былач кешесенә кул күтәрүнең ни икәнен күрсәтермен мин сезгә! – дип, кызу-кызу атлап китеп барды.

– Безгә күрсәтәсе килгән нәрсәңне авыл савитына үзем дә күрсәтешермен, җәме! – дип кычкырды да, икенче аягындагы чабатаның бавын чишкән уңайга, инде күзен шаян җемелдәтеп, Хәдичәгә текәлде Мәрфуга. – Ниемә дип тота да сиңа бәйләнә соң ул, ә? Минем чабата гаебе дә синең җилкәңә төште.

– Бәйләнми ни, аңа әле һаман теше үтми бит... – Хатыннарның берсе пышылдап кына нидер әйтте дә дәррәү килеп көләргә дә тотындылар. Йөзе кызарып киткән Хәдичә, балаларга ымлап, бармагын иренενә куйды. Тик Асия белән Гөлсәйдәнең инде олыларда эше юк иде, алар Мирхәт артыннан тын да алмый карап тордылар да үз сорауларына җавап эзләп мәш килделәр. «Үзе сиңа эт баласы ди, үзе бүре кебек карый ди. Әллә исәр инде бу Мирхәт абый?» Асиянең шулай диюе ике кызны тәмам уйга салды, алар, гаепләре турында бөтенләй онытып, җитәкләшеп тагын инешкә таба йөгерделәр.

– Бала-чага алдында әллә ниләр сөйләшмәгез инде, кызлар.

Хәдичәнең шулай диюенә әрем телле Сәкинә исемле хатын:

– И-и, җаным, без бит синең кебек мулла кызы түгел, культур-мультур итеп сөйләшә белмибез, – дип төрттерде.

Ул көнне кичке караңгылык тәмам канат җәйгәч кенә таралыштылар.

Өйгә кайтып керүгә, Хәдичә тиз-тиз генә бәрәңге пешерергә утыртты, кулын юып, кәҗәләрне савып алды. Кабыклы бәрәңгене кәҗә сөте белән бөкләп куйганнан соң Сәет белән Гөлсәйдә тәмам арыган-алҗыган кыяфәттә сәкегә аудылар. Сәет җәйгә чыгу белән колхозның ат абзарына эшкә йөри башлаган иде, араннарны чистарту, тирес чыгару – аксак Нурулла карт белән яшүсмер Сәет өстендә. Тегесе хәйләкәр, аягын сөйрәп зарланырга тотына да таякның авыр башы Сәетнең иңнәренә төшә. Кич өйгә кайтып егылганда, малайның җеп өзәрлек тә хәле калмый, авызына берәр ризык эләгүгә, ятып йоклау ягын гына карый.

Хәдичә улының кабыргалары беленеп торган ябык аркасыннан сөеп, өстенә иске җәймәне каплады да үзе, авыр сулап, сәкенең бер читенә утырды. Гөлсәйдә чәче тузгыган башын әнкәсенең итәгенә шуыштырды, сирәк әләккән мондый бәхеттән берара изрәп ятты.

Шулвакыт каты гына итеп ишек какканга өчесе дә дертләп киттеләр.

– Бу вакытны ни калган инде? – дип үзалдына сөйләнә-сөйләнә, Хәдичә өйалды ишеген генә ачты да: – Кайсыгыз анда? – дип кычкырып эндәште.

– Хәдичә апа, бу мин, Фәгыйлә. – Кәнсә җыештыручы икән. Хәдичә, аның тавышын танып, ишек келәсен күтәрде. – Сине кәнсәгә чакырталар, анда теге кем, ни, агент килгән, заем түләмәүчеләрне җыялар.

– Чукындылар инде шул заемнары белән, әйтмәсәм дә булмады, тәүбә әстәгъфирулла... – Хәдичәне заем дип инде өченче тапкыр чакырулары, юк акчаны каян алып түләргә икәнлеген генә өйрәтүче юк. – Карале, апаем, агент дигәнең ирме, хатынмы?

– Теге юлы да шул адәм килгән ие бит, башы кабак чаклы, үзе пеләш – шул инде. – Шуны да белмисеңмени дигәндәй, Фәгыйлә тавышын уйнаклатып алды да чыгып та йөгерде.

Теге юлы диген... Ул пеләшнең майлы күзен онытмаганга сорады да инде Хәдичә бу юлы кем килгәнлеген...

– Балалар, торыгыз әле. Җәһәт кенә кәнсәгә менеп төшик, тынгы бирмәсләр.

Сәет тә, Гөлсәйдә дә әниләренә каршы дәшмәделәр, мыштым гына сәкедән шуып төштеләр.

Болдырга сөялгән себеркедән берничә ботак сындырып, тышкы яктан ишек келәсенә кыстырып бикләделәр дә өчәүләп капкадан чыгып киттеләр.

Әниләренең ачуы чыкканы аның дәшми генә җил-җил атлавыннан сизелә, Гөлсәйдә абыйсы белән әнисе артыннан йөгереп тә чак җитешеп бара. Кәнсә дигәннәре өске урамда, элекке Әшраф мулла өендә урнашкан, барып җиткәнче ярыйсы теркелдәделәр. Бакчада кайчандыр күкрәп үскән алмагачларны кисеп аткач, аның тирә-ягы ничектер шыксызланып, шомлы булып калган иде. Җитмәсә, сугыш башланганнан бирле кичләрен ут алганнан соң тәрәзәләрне томалап кую мәҗбүри – элек кашага бизәкләрен балкытып, гөл чәчәгедәй балкып утырган йортның кара тәрәзәләре һәркемне кабып йотарга әзерләнгән аждаһа авызы булып күренә.

Алар өчәүләп килеп кергәндә, коридорда кеше-кара юк иде. Хәдичә башын эчкә тыгып, үзенең килүен әйтте дә, «Әйдә, кер, Әкрамова», – дигәнне ишеткәч, ике баласын җитәкләп, эчкә үтте. Агач өстәлдә сүрән генә булып куыклы лампа яна, тәрәзә янындагы артсыз урындыкта, авызын җигүле ат кереп китәрдәй итеп ачып иснәнә-иснәнә, авыл советы рәисе Шәйдулла утыра. Өстәл артына исә, чыннан да, кабак баш – районнан килгән Габитов фамилияле алып гәүдәле адәм урнашкан. Ирләрнең икесенең дә йөзе чөегендер төсенә кергән, шәпләп кенә көмешкә белән сыйланырга өлгергәннәр, ахры.

– Бу ике төенчегеңне нигә өстерәп йөрисең? Үзең генә кер! – дип борын астыннан мыгырданды Шәйдулла, Сәет белән Гөлсәйдәгә ымлап.

Хәдичә, киресенчә, балаларының учын катырак итеп кысты да, заемың түләнмәгән дип тегеләр һөҗүм иткәнче үк:

– Акча да юк, күкәй дә, сөт тә, йон да юк. Аны үзем генә кереп әйттем ни, балалар белән кердем ни – барыбер бер җавап түгелмени? – диде каушап тошмичә.

Кабак баш бүлмәне дер селкетеп төчкереп куйды, аннан пеләшен учы белән сыпыра-сыпыра:

– Син бит – кулак кызы, ничек инде синең акчаң булмасын? – диде, майлы күзен яшь хатынның сылу йөзе, зифа гәүдәсе буйлап йөгертеп алгач. – Әллә кай җирләреңә яшереп бетергәнсеңдер әле алтыннарыңны.

– Ул алтыннарны тапсаң, миңа да күрсәтерсең әле, җәме, иптәш начальник, – дип, ачы көлемсерәде Хәдичә, соңгы сүзләренә басым ясап.

Габитов урыныннан сикереп торды да, өстәл тирәли дөп-дөп йөренеп алгач, кинәт кенә Шәйдулла алдына килеп басты. Көмешкә парыннанмы, йокысы килүдәнме үзалдына оеп утырган ир калгып китте.

– Слушай, Шәйдул, нәрсә бу, авылыгызда хатыннар кем белән ничек сөйләшергә икәнен белми башладылармы әллә? Но-но, өйрәтермен мин сезне, җыен контра... Иртәгә үк монысын да мәҗбүри эшкә озатасың! Ишеттеңме, иртәгә үк! – Габитов, авыл советы рәисенең йөзенә җирәнгән кыяфәттә текәлеп торды да Хәдичәгә борылып, мыскыллы елмайды. – Түлке анда балаларыңны җитәкләп барма, үскәнем, үзең үк үкенерсең, ха-ха-ха...

Хәдичә башта аптырап калды. Әллә кая еракка озатсалар, балаларым нишләр, дигән уй мизгел эчендә миен ярып үтте. Ул арада Шәйдулла урыныннан торды, тез өстенә яткан кепкасын маңгаена ук батырып киде, авызын җәеп, ямьсез итеп иснәде дә өстәл янына барып, андагы кәгазьгә нидер язып куйды.

– Апаем, ни, иртәгә җыелып китәсез. Пучыга юл төзү эшенә эшче көчләр кирәк...

Рәиснең кеше төсле тон белән эндәшүе ярамадымы, Габитов йодрыгы белән дык итеп өстәл читенә сукты.

– Нәрсә син җыенысы белән мәмкәләнеп торасың? Моның ише кулак калдыкларын җир казырга гына түгел, ераккарак озатыр идем әле мин... Ничава, бераз тәртипкә өйрәнеп кайтыр, яңадан үзе үк «Габитов абыкаем» дип шуышып килердәй булыр. Андыйларны гына күргән бар.

Пучыга дигәнне ишеткәч, Хәдичә эченнән генә җиңел сулап куйды. Ике авыл арасы, күп булса, унике-ундүрт чакрым бардыр. Җир чите түгел, ничек тә түзәрләр әле.

Габитовның сүзе бетмәгән икән. Сөйләшергә сусаган мәле булдымы, үзенең кемлеген күрсәтергә теләве идеме – ишекле-түрле йөргән җиреннән, әле Шәйдулла, әле Хәдичә алдында шып туктап, «сез наданнар, шуны да белмисез» дигән тон белән сөйләнә бирде. Әллә берәр кайда сөйлисе докладына репетиция ясавы булды инде – анысы аңлашылмады.

– Сез сугыш чорында яшәгәнегезне онытып җибәрәсез! Берегездә бер җаваплылык юк, ил язмышы турында кайгырту юк! Ничекләр барысын җайга салып бетерергә, сез миңа менә шуны әйтегез! Техника белән нишләргә? Тракторлар аз, механизаторлар тәҗрибәсез, булган авыл хуҗалыгы машиналарын ремонтлау эше начар. Чәчүгә чыкканда сабаннарның 31 проценты, чәчкечләрнең – 77, тырмаларның – 77, культиваторларның – 34,8, арбаларның 40 проценты гына ремонтланган иде. Шушы хәлдә дә чәчүне ерып чыктык бит, ә, әйме, Шәйдул?

Әрле-бирле йөренгән Габитовның сәер ялтыраган күзләренә, кызгылт йөзенә балалар шаккатып карап торса, аның авызыннан яңгыраган сүзләргә Шәйдулла ни дип җавап кайтарырга белми, берара ык-мык килеп торды, тирләп чыккан башын сөртеп алды.

– Анысы шулай, иптәш Габитов, ерып чыктык. Безнең трактористка Миңсылуны район газетасында дә яздылар бит: үз сменасында норма буенча көнгә 4,2 гектар урынына 5,2–6,4 гектар җир сөрде, малай! Биш көндә заданиене 140 процентка үтәп, ягулыкка 39 килограмм экономия ясады.

Бу ике ирнең, хисап җыелышында утыргандай һәм бер-берсе белән «минбәләмлектә» ярышкандай, саннар белән сөйләшүеннән Хәдичәнең башы тубал булды, ул капыл кыймылдап чыгып китүне килештермичә, тыңлаган кыяфәт белән басып торды да, түзмәде, башын югары күтәреп, балаларының кулын әле һаман ычкындырмаган килеш, коридорга атлады.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе, туганы

НИГЪМӘТҖАНОВ
Ренат Рафаэль улының

вакытсыз вафат булуы сәбәпле, Татарстан Республикасы Рәисенең Документлар белән тәэмин итү контроль идарәсе контроль бүлегенең өлкән белгече Нигъмәтҗанов Руслан Рафаэль улының авыр кайгысын уртаклаша.

СИН, ДОЛЛАР, ӘЛЛӘ НИШЛӘДЕҢ

1990 нчы елларда миллион доллар турында хыялланган кешеләргә бүген өчлатә авыр.

* * *

– Ишеттеңме, «Всё по 100» кибетенә доллар китергәннәр.

* * *

Кесәмнән яшел валюта төшеп китте. Аны күтәргән арада, ул берничә сумга артты.

* * *

– Их, долларымны иртәрәк сатканмын! Ярый икенчесен саклап калдым.

* * *

Банкта «Долларлар бетте» дигән язу күргәч, Американы җәлләп куйдым.

* * *

Ярый әле быел диңгезгә барасым юк.

* * *

– Бер миллион доллар отсагыз, нишләячәксез?
– Еврога алыштырам.

* * *

Бөтен нәрсә дә долларга бәйле түгел. Мәсәлән, хезмәт хакы.

Әз-мәз мәзәк

– Робот тузан суырткыч алган идең. Әйбәт кенә эшлиме?
– Әйе. Әмма «домой» дигән төймәгә баскач, бүлмә буйлап арлы-бирле йөри, Кытайга юл эзли бугай.

* * *

– Туй балдагы белән, ай-һай, ялгыштым, дустым.
– Бармагы белән ялгыштыңмы?
– Кешесе белән.

* * *

Әнисе кызын орыша:
– Менә мин кечкенә чакта бер дә алдамый идем!
– Ә ничә яшьтән алдый башладың?

* * *

– Мин надан кешеләр белән сөйләшергә яратмыйм.
– Дөрес, үз-үзең белән сөйләшү бер дә килешми.



Сканворд җаваплары

Горизонталь: ухa, айгыр, ара, ашлама, Ык, ми, кунак, утар, Бариев, Йемен, арпа, Нина, сквер, ал, кода, Си, каяк, адаш, песи, им, ант, Арина, Сакко, кашык, иния, Лев, елан, ун, кратер, Ра, ярсу, берүк, Сәрия, акр, Халк, китмә, ук, АН, Дик, Ани, ияк, Арслан.

Вертикаль: сканер, шалкан, Лас, Вятка, читек, анар, аш, Камалова, Арыш, якудза, Радик, ки, ягулык, план, урак, кис, акула, Шаинский, ял, Урам, урт, ака, Рамай, оптик, Ман, апа, икенде, яр, Хәния, Миасс, аба, уен, Иа, тел, ТНА, клерк, сикерү, Рәхимов.

Беләсең килсә...

1 Һавада азот күләме ничә процент тәшкил итә?
а) 78%;
б) 12%;
в) 31%.

2 «Титаник» ничәнче елда төпкә киткән?
а) 1910;
б) 1911;
в) 1912.

3 Кубның ничә кабыргасы бар?
а) 8;
б) 12;
в) 16.

4 Бүгенге Яшел Үзән районы Олы Шырдан авылында кем туган?
а) Каюм Насыйри;
б) Габдулҗаббар Кандалый;
в) Мәүлә Колый.

Җаваплар: 1-а); 2-в); 3-б); 4-а).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 14057 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 317

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+